ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

КАРАР
19 нчы октябрь 2020 ел

РЕШЕНИЕ
№ 19

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясының 13 өлеше, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, гавами тыңлаулар беркетмәләрен һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кушымта итеп бирелгән Генераль планын расларга.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘЛДЕРМЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ

РАСЛАНА ТОРГАН ӨЛЕШ

1 том

Территориаль планлаштыру турында нигезләмәләр

2020 ел

ЭЧТӘЛЕК

ПРОЕКТНЫҢ СОСТАВЫ 4

1. КЕРЕШ 5

1.1. Генераль планның максатлары һәм бурычлары ..... Ошибка! Закладка не определена.

2. ТЕРРИТОРИАЛЬ ПЛАНЛАШТЫРУ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘЛӘР 6

2.1. Җирлекнең җирле әһәмияттәге, муниципаль районның җирле әһәмияттәге, региональ әһәмияттәге, федераль әһәмияттәге урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектларының төрләре, билгеләнеше һәм исемнәре турында белешмәләр, аларның төп характеристикалары һәм урнашу урыны 6

2.2. Функциональ зоналар 9

2.3. Планлаштырылган объектларны урнаштыруга бәйле рәвештә мондый зоналарны билгеләү таләп ителгән очракта территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристика 11

3. ТОРАК ПУНКТОВ ПУНКТЛАРНЫҢ ЧИКЛӘРЕ 12

ПРОЕКТНЫҢ СОСТАВЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегенең Генераль планы түбәндәге составта эшләнде:

Раслана торган өлеш

Текстлы материаллар:

№ т/б	Исеме	Том
1	Территориаль планлаштыру турында нигезләмәләр	1

График материаллар:

Бит №	Исеме	Том	Масштаб
1	Җирлекнең җирле әһәмияттәге объектларын планлаштырып урнаштыру картасы	2	1:10 000
2	Җирлекнең функциональ зоналары картасы	2	1:10 000
3	Торак пунктлар чикләре картасы	2	1:10 000

Кушымта

№ т/б	Исеме	Том
1	Торак пунктларның чикләре турында белешмәләр	–

Генераль планны нигезләү материаллары

Текстлы материаллар:

№ т/б	Исеме	Том
1	Аңлатма язуы	3

График материаллар:

Бит №	Исеме	Том	Масштаб
1	Җирлек территориясеннән хәзерге файдалануның картасы	4	1:10 000
2	Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләренең картасы (гамәлдәге торышы)	4	1:10 000
3	Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре картасы (проект тәкъдиме)	4	1:10 000

1. КЕРЕШ

Әлеге проект Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 декабрендәге 38 нче номерлы Карары белән расланган Әлдермеш авыл җирлегенең Генераль планына алмашка эшләнә.

Проектның заказчысы - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Башкарма комитеты.

Проектны эшләүче - "Максима" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте.

Проект 2040 елга кадәр исәп-хисап срогына әзерләнгән, гамәлгә ашыру этаплары ачыкланмаган.

1.1. Генераль планның максатлары һәм бурычлары

Генераль планны эшләүнең төп максатлары түбәндәгеләр:
- җирлекнең шәһәр төзелешен үстерүнең юнәлешен билгеләү һәм тәэмин итү;
- авыл җирлеген җирле дәрәҗәдәге шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү.

Проект бурычларына түбәндәгеләр керә:
- авыл җирлеге территориясен комплекслы бәяләү;
- торак пунктларның чикләрен корректировкалау;
- җирлек территориясен функциональ зоналаштыру, функциональ зоналарның параметрларын билгеләү;
- торак төзелеше мөмкинлеге булган территорияләрне билгеләү;
- җитештерү функциясен үстерү өчен территорияләрне билгеләү;
- транспорт инфраструктурасын үстерү;
- халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсен үстерү.

Генераль планның проект карарлары Әлдермеш авыл җирлегенең һәм Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше планнарын формалаштыру яки корректировкалау, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү, территорияне планлаштыру өчен нигез булып тора.

2. ТЕРРИТОРИАЛЬ ПЛАНЛАШТЫРУ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

2.1. Җирлекнең җирле әһәмияттәге, муниципаль районның җирле әһәмияттәге, региональ әһәмияттәге, федераль әһәмияттәге урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектларының төрләре, билгеләнеше һәм исемнәре турында белешмәләр, аларның төп характеристикалары һәм урнашу урыны

1 нче таблица

карталарда №	Төре	Билгеләнеше һәм исеме	Төп характеристикалары	Урнашкан урыны	Функциональ зона
Җирлекнең җирле әһәмияттәге объектлары					
1	Спорт объекты	Спорт залы	проект егәрлеге - идән мәйданы 288 кв. м	Сая ав.	күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле
2	Спорт объекты	Яссылыклы корылма	проект егәрлеге - идән мәйданы 162 кв. м	Өбрә ав.	күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле
3	Спорт объекты	Яссылыклы корылма	проект егәрлеге - идән мәйданы 2400 кв. м	Әлдермеш ав. көнчыгышка	рекреация билгеләнешендә
4	Агросәнәгать комплексы объекты	Авыл хуҗалыгы җитештерүенең төрле төрләре булган агросәнәгать комплексы предприятиесе	проект егәрлеге – 50 башка кадәр	Өбрә ав. төньяк-көнчыгышка	авыл хуҗалыгы предприятиеләренең һәм авыл хуҗалыгын тәэмин итү объектларының җитештерү зонасы
5	Агросәнәгать комплексы объекты	Авыл хуҗалыгы продукциясен саклау склады	–	Әлдермеш ав. төньяк-көнбатышка	авыл хуҗалыгы предприятиеләренең һәм авыл хуҗалыгын тәэмин итү объектларының җитештерү зонасы
6	Махсус билгеләнешле объект	Зират (киңәйтү)	киңәйтү мәйданы– 0,27 га	Өбрә ав.көньяк-көнбатышка	зиратлар
7	Махсус билгеләнешле объект	Зират (киңәйтү)	киңәйтү мәйданы– 0,27 га	Сая ав. төньякка	зиратлар
Муниципаль районның җирле әһәмияттәге объектлары					
8	Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы	Башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе составындагы балалар бакчасы	проект егәрлеге – 25 урын	Сая ав.	күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле
9	Гомуми белем бирү оешмасы	Балалар бакчасы белән берләштерелгән башлангыч гомум белем бирү мәктәбе	проект егәрлеге – 25 урын	Сая ав. (гамәлдәгесенә алмашка)	күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле

10	Өстәмә белем бирү оешмасы	Өстәмә белем бирү учреждениесе	проект егәрлеге – 50 урын	Әлдермеш ав.	күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле
11	Өстәмә белем бирү оешмасы	Өстәмә белем бирү учреждениесе	проект егәрлеге – 40 урын	Сая ав.	күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле
12	Беренчел медик-санитар ярдәме күрсәтүче медицина оешмасы бүлекчәсе	Фельдшер-акушерлык пункты	проект егәрлеге – 10 смен.килүче	Өбрә ав. (гамәлдәгесенә алмашка	күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле
13	Микробиологик, азык-төлек, азык-төлек-тәм сәнәгате предприятиесе	Ярмалар җитештерү предприятиесе	–	Өбрә ав.төньяк-көнчыгышка; 16:16:030403:59 җир кишәрлеге чикләрендә	сәнәгать предприятиеләре җитештерү зонасы
14	Микробиологик, азык-төлек, азык-төлек-тәм сәнәгате предприятиесе	Он җитештерү предприятиесе	–	Өбрә ав.төньяк-көнчыгышка; 16:16:030403:59 җир кишәрлеге чикләрендә	сәнәгать предприятиеләре җитештерү зонасы
15	Микробиологик, азык-төлек, азык-төлек-тәм сәнәгате предприятиесе	Икмәк пешерү җитештерүе	–	Өбрә ав.төньяк-көнчыгышка; 16:16:030403:59 җир кишәрлеге чикләрендә	сәнәгать предприятиеләре җитештерү зонасы
16	Микробиологик, азык-төлек, азык-төлек-тәм сәнәгате предприятиесе	Чималны саклау урыннары булган җиләк-җимеш продукциясен эшкәртү һәм консервлау цехы, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге эшкәртү цехлары	территория мәйданы – 3,0054 га	Сая ав. төньяк-көнчыгышка; 16:16:030402:225 җир кишәрлеге чикләрендә	сәнәгать предприятиеләре җитештерү зонасы
17	Төзелеш сәнәгате предприятиесе, металл булмаган минераль продукция чыгару буенча	Товар бетоны, брусчаткалар һәм төзелеш блоклары җитештерү заводы	территория мәйданы – 5,18 га	Сая ав. төньяк-көнчыгышка; 16:16:030402:160 җир кишәрлеге чикләрендә	сәнәгать предприятиеләре җитештерү зонасы

18	Химия, фармацевтика сәнәгате предприятиесе, полиграфия предприятиесе	Кремний кушылмалары силикатлары нигезендә көнкүреш һәм техник химик продуктлар, төзелеш материалларына өстәмәләр җитештерү цехы	территория мәйданы – 1,927 га	Сая ав. төньяк-көнчыгышка; 16:16:030402:217 җир кишәрлеге чикләрендә	сәнәгать предприятиеләре җитештерү зонасы
Региональ (республика) әһәмияттәге объектлар					
19	Транспорт инфраструктурасы объекты	«Казан транспорт төенен урап узу» әйләнә автомобиль юлының көньяк участогы	өслеге – асфальт-бетон; категориясе – II; озынлыгы – 2113 м	Әлдермеш авыл җирлеге	транспорт инфаструктурасы
Федераль әһәмияттәге объектлар					
Объектларны урнаштыру планлаштырылмый					

2.2. Функциональ зоналар

Таблица 2

Зонаның исеме	Зонаның функциональ билгеләнеше	Зонаның параметрлары	Зонада җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдаланырга мөмкин төрләрнең кодлары *
Индивидуаль торак йортлар салу зонасы	- индивидуаль торак төзелеше; - зур булмаган территорияләрне биләп торучы һәм торак төзелеше территориясендә урнашкан социаль, иҗтимагый һәм эшлекле билгеләнештәге, инженерлык инфраструктурасы объектлары	Төп төзелештәге катларның иң чик саны: 3 (мансардны кертеп); төзелеш коэффициенты: 0,3 кәчә:	2.1; 2.2; 2.3; 2.7; 2.7.1; 12.0
Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона	мәдәният, мәгариф, спорт, сәламәтлек саклау, социаль тәэминат, сәүдә, җәмәгать тукланыу, көнкүреш һәм кунакханә хезмәте күрсәтү объектлары; административ, фәнни-тикшеренү учреждениеләре; культ биналары	Төп төзелештәге катларның иң чик саны: 5 (мансардны кертеп); төп төзелешнең чик биеклеге: 20 м; төзелеш коэффициенты: 1гәчә	2.7; 2.7.1; 3.0; 4.0; 5.1; 12.0 - 12.1
Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләре зонасы	- бакчалар; - яшелчә бакчалары	Төп төзелештәге катларның иң чик саны: 3 (мансардны кертеп); төп төзелешнең чик биеклеге: 10 м;	2.7.1; 13.0; 13.1 - 13.2
Рекреацион билгеләнешле зона	- ял базалары һәм йортлары; - балалар лагерьлары; - яхт-клублар, көймә станцияләре - спорт инвентаре прокаты базасы - спорт базалары; - физкультура-савыктыру объектлары; - туризм объектлары	билгеләнмиләр	5.0; 9.0 - 9.3
Сәнәгать предприятиеләренең җитештерү зонасы	- IV һәм V класслы хәвефле сәнәгать җитештерүе объектлары; - санитар-яклау зонасы проектын җитештергәндә һәм эшләгәндә алдынгы технологик чаралардан файдалану шарты белән башка класслы хәвефле сәнәгать җитештерүе объектлары	төзелеш коэффициенты: 0,8 гәчә	6.1 - 6.6; 6.9; 6.11; 10.1
	- файдалы казылмалар чыгару объектлары	билгеләнмиләр	
Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең җитештерү зонасы һәм авыл хуҗалыгын тәэмин итү объектлары	- IV һәм V класс хәвефле авыл хуҗалыгы җитештерүе объектлары; - санитар-яклау зонасы проектын җитештергәндә һәм эшләгәндә алдынгы технологик чаралардан файдалану шартларында, башка класслы авыл хуҗалыгы җитештерүе объектлары	төзелеш коэффициенты: 0,8 гәчә	1.7 - 1.18

	- авыл хуҗалыгын тәэмин итү объектлары	төзелеш коэффициенты: 0,6 гача	
Инженерлык инфраструктурасы һәм коммуналь хезмәт күрсәтү зонасы	- торак пунктларны электр, газ, җылылык, су белән тәэмин итү, су бүлү объектлары; - антенна-мачта корылмалары, элемтә объектлары; - гидротехник корылмалар; - магистраль торба үткәргечләрдә объектлар; - янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү объектлары; - чүп эшкәртү предприятиеләре; - кар саклау һәм эшкәртү объектлары	билгеләнмиләр	3.1; 3.9.1; 6.7 - 6.8; 7.5; 11.3; 12.2
Транспорт инфраструктурасы зонасы	- каты өслекле автомобиль юллары; - вокзаллар, автомобиль транспорты станцияләре; - автомобиль ягулык салу станцияләре - автотранспортка, юл буе сервисына хезмәт күрсәтү объектлары - транспорт саклау объектлары; - тимер юл вокзаллары һәм станцияләр; -причаллар, пристаньнар, елга вокзаллары; - аэропортлар, аэродромнар, очып китү-утыру полосалары һәм мәйданчыклар	билгеләнмиләр	2.7.1; 4.9; 4.9.1; 5.4; 7.1 - 7.4; 12.0
Махсус билгеләнештәге зона	- биотермик чокырлар; - себер язвасы базлары; - каты коммуналь калдыкларның полигоннары һәм чүплекләре	билгеләнмиләр	12.2
Зиратлар зонасы	- зиратлар	билгеләнмиләр	12.1
Торак пунктларны яшелләндерү зоналары	- торак пунктларда үзе чәчүле яшел үсентеләр; - гомуми кулланылыштагы яшелләндерелгән территорияләр	яшелләндерүнең минималь дәрәҗәсе: 65 %	12.0
Авыл хуҗалыгы җирләре зонасы	- авыл хуҗалыгы җирләре; - җәйге лагерьлар, терлекләр өчен утарлар; - авыл хуҗалыгы җирләре территориясендә күчмә өслекле, япмасыз автомобиль юллары; - кыр юллары	билгеләнмиләр	1.1; 1.19 – 1.20
Урманнар, башка үсемлекләр зонасы	- урманнар; - киселгән урыннар; - торак пунктлардан тыш куаклыклар; - күчеш белән капланган, урманнар территориясендә өслексез автомобиль юллары; - урман юллары	билгеләнмиләр	1.17; 10.0
Акваторияләр зонасы	- өске су объектлары; - сазлыклар	билгеләнмиләр	11.0

* Россия Икътисади үсеш министрлыгының "Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында" 01.09.2014 № 540 боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре Классификаторы нигезендә (Россия Икътисади үсеш министрлыгының 2019 ел 04.02 44 номерлы Приказы редакциясендә)

2.3. Планлаштырылган объектларны урнаштыруга бәйле рәвештә мондый зоналарны билгеләү таләп ителгән очракта территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристика

Планлаштырылган объектларны урнаштыруга бәйле рәвештә таләп ителә торган территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар турындагы белешмәләр аларның характеристикалары 3 нче таблицада китерелгән.

3 нче таблица

Зонаның исеме	Чыганак исеме	Зона күләме, м
Санитар-саклау зонасы	Товар бетоны, брусчаткалар һәм төзелеш блоклары җитештерү заводы	300
Санитар-саклау зонасы	Кремний кушылмалары силикатлары нигезендә көнкүреш һәм техник химик продуктлар, төзелеш материалларына өстәмәләр җитештерү цехы	100
Санитар-саклау зонасы	Ярмалар җитештерү предприятиесе	100
Санитар-саклау зонасы	Он җитештерү предприятиесе	100
Санитар-саклау зонасы	Чималны саклау урыннары булган җиләк-җимеш продукциясен эшкәртү һәм консервлау цехы, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге эшкәртү цехлары	50
Санитар-саклау зонасы	Икмәк пешерү предприятиесе	50
Санитар-саклау зонасы	Авыл хуҗалыгы җитештерүенең төрле төрләре булган агросәнәгать комплексы предприятиесе (50 башка кадәр)	50
Санитар-саклау зонасы	Авыл хуҗалыгы продукциясен саклау склады	50
Санитар-саклау зонасы	Зиратлар	50
Автомобиль юлларының юл буе полосалары	Автомобиль юллары I – II категорияле («Казан транспорт төенен урап узу» әйләнә автомобиль юлының көньяк участогы)	75

Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарның күләменә һәм конфигурациясенә әлеге зоналар проектларын эшләүгә бәйле рәвештә төгәллек кертелергә мөмкин.

3. ТОРАК ПУНКТЛАРНЫҢ ЧИКЛӘРЕ

Торак пунктларның гамәлдәге чикләре Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Әлдермеш авыл җирлеге Советы карары белән расланган Әлдермеш авыл җирлегенең 2012 елның 12 декабрендәге 38 номерлы Генераль планы белән билгеләнгән.

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында торак пунктлар чикләре турында белешмәләр юк..

Әлеге проект нигезләмәләрен гамәлгә ашыру өчен Әлдермеш ав., Өбрә ав., һәм Сая ав. торак пунктлары чикләрен үзгәртү таләп ител.

Торак пунктларның гамәлдәге һәм планлаштырыла торган чикләре әлеге проектның график материаллары составындагы торак пунктлар чикләре Картасында чагылдырылды.

Торак пунктларның чикләрен үзгәртү күздә тотыла торган территорияләрнең участоклары торак пунктларның чикләре Картасында һәм 4 нче таблицада күрсәтелгән.

4 нче таблица

Торак пункт	Картадагы участок №	Мәйданы, га
Әлдермеш ав.	1	+81,24
	2	+31,448
	3	+17,137
	4	+14,024
	5	-8,493
	6	-7,654
	7	-5,991
	8	+5,225
	9	-4,905
	10	-3,632
	11	-2,408
	12	+0,314
	13	+0,303
	14	+0,182
Өбрә ав.	15	+5,594
	16	-2,154
	17	-1,436
	18	-0,341
	19	-0,127
	20	-0,117
	21	+0,518
Сая ав.	22	-10,616

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘЛДЕРМЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ

ГЕНЕРАЛЬ ПЛАННЫ НИГЕЗЛӘҮ БУЕНЧА МАТЕРИАЛЛАР

3 том

Аңлатма язуы

2020 ел

ЭЧТӘЛЕК

ПРОЕКТНЫҢ СОСТАВЫ....16
1. КЕРЕШ....17
1.1. Генераль планның максатлары һәм бурычлары....17
1.2. Комплекслы социаль-икътисадыйүсеш планнары һәм программалы, шәһәр төзелеше документлары һәм файдаланыла торган материаллар турында белешмәләр.17
1.3. Җирлекнең кыскача характеристикасы....19
2. ҖИРЛЕК ТЕРРИТОРИЯСЕНЕҢ БҮГЕНГЕ ТОРЫШЫ ҺӘМ ФАЙДАЛАНЫЛУЫНА АНАЛИЗ. ГЕНЕРАЛЬ ПЛАН ЧАРАЛАРЫН НИГЕЗЛӘҮ....20
2.1. Торак фонды....20
2.2. Социаль, иҗтимагый һәм эшлекле билгеләнештәге объектлары....20
2.3. Сәнәгать предприятиеләре һәм объектлары....25
2.3.1. Сәнәгать җитештерүе объектлары 25
2.3.2. Чыгару сәнәгате предприятиесе һәм объектлары 26
2.4. Авыл хуҗалыгы, балык тоту һәм балык үрчетү предприятиеләре һәм объектлары....26
2.4.1. Авыл хуҗалыгы җитештерүе, балык тоту һәм балык үрчетү предприятиеләре 26
2.4.2. Авыл хуҗалыгын тәэмин итү объектлары 26
2.5. Склад объектлары....27
2.6. Зиратлар, махсус билгеләнешле объектлар....27
2.7. Ял һәм туризм объектлары....30
2.8. Транспорт инфраструктурасы....31
2.8.1. Автомобиль транспорты 31
2.8.2. Тимер юл транспорты 32
2.8.3. Су транспорты 32
2.8.4. Һава транспорты 32
2.8.5. Торба үткәргеч транспорты 33
2.9. Инженерлык инфраструктурасы һәм коммуналь хезмәт күрсәтү....33
2.9.1. Магистраль инженерлык коммуникацияләре 33
2.9.2. Электр белән тәэмин итү 33
2.9.3. Газ белән тәэмин итү 33
2.9.4. Су белән тәэмин итү 34
2.9.5. Су бүлү 35
2.9.6. Җылылык белән тәэмин итү 35
2.9.7. Элемтә 35
2.9.8. Коммуналь калдыкларны чыгаруны оештыру 35
2.9.9. Янгын куркынычсызлыгы 36
3. ТОРАК ПУНКТЛАРНЫҢ ЧИКЛӘРЕ....37

3.1. Торак пунктларның чикләрен үзгәртү нигезләмәсе 37

3.2. Торак пунктлар чикләреннән чыгарыла торган торак пунктлар чикләренә кертелә торган җир кишәрлекләре исемлекләре 38

3.3. Торак пунктларның билгеләнгән чикләреннән читтә урнашкан һәм торак пунктлар чикләренә кертелергә тәкъдим ителми торган "торак пунктлар җирләре" җирләр категориясенең җир кишәрлекләре.....46

4. МӘДӘНИ МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫ.....51

5. МАХСУС САКЛАУЛЫ ТАБИГЫЙ ТЕРРИТОРИЯЛӘР. Ошибка! Закладка не определена.

6. ТЕРРИТОРИЯДӘН ФАЙДАЛАНУНЫҢ МАХСУС ШАРТЛАРЫ БУЛГАН ЗОНАЛАР 52

7. ТАБИГЫЙ ШАРТЛАР ҺӘМ ЭКОЛОГИК СИТУАЦИЯ 55

7.1. Табигый шартлар һәм ресурслар 55

7.1.1. Рельеф 55

7.1.2. Файдалы казылмалар 55

7.1.3. Гидрогеологик шартлар 55

7.1.4. Өске һәм җир асты сулары 55

7.1.5. Климат характеристикасы 56

7.1.6. Инженер-геологик шартлар 57

7.1.7. Ландшафт, туфрак катламы, үсемлекләр 57

7.2. Әйләнә-тирә мохит торышын бәяләү.....57

7.2.1. Атмосфера һавасының торышы 57

7.2.2. Су ресурсларының торышы 57

7.2.3. Туфрак катламы һәм җир ресурсларының торышы 58

7.2.4. Җитештерү һәм куллану калдыклары, биологик калдыклар 58

7.2.5. Йогынтыларның физик факторлары 58

7.2.6. Яшел утыртмаларның торышы 59

7.3. Экологик ситуацияне оптимальләштерү буенча чаралар 59

8. ТАБИГЫЙ ҺӘМ ТЕХНОГЕН ХАРАКТЕРДАГЫ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР ТУУ КУРКЫНЫЧЫ ТӨП ФАКТОРЛАРЫНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ ҺӘМ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ 63

8.1 Җирлек территориясенә йогынты ясарга мөмкин булган табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр чыганаклары исемлеге.....63

8.2. Җирлек территориясендә, шулай ук җирлек территориясенә якын җирдә техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр чыганаклары исемлеге 67

8.3. Җирлек территориясендә биологик-социаль характердагы гадәттән тыш хәлләр чыганаклары исемлеге.....70

8.4. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар исемлеге 70

9. ТӨП ТЕХНИК-ЭКОНОМИК КҮРСӘТКЕЧЛӘР 72

ПРОЕКТНЫҢ СОСТАВЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Генераль планы түбәндәге составта эшләнгән:

Раслана торган өлеш

Текстлы материаллар:

№ т/б	Исеме	Том
1	Территориаль планлаштыру турында нигезләмәләр	1

График материаллар:

Бит №	Исеме	Том	Масштаб
1	Җирлекнең җирле әһәмияттәге объектларын планлаштырып урнаштыру картасы	2	1:10 000
2	Җирлекнең функциональ зоналары картасы	2	1:10 000
3	Торак пунктлар чикләре картасы	2	1:10 000

Кушымта

№ т/б	Исеме	Том
1	Торак пунктлар чикләре турында белешмәләр	–

Генераль планны нигезләү материаллары

Текстлы материаллар:

№ т/б	Исеме	Том
1	Аңлатма язуы	3

График материаллар:

Бит №	Исеме	Том	Масштаб
1	Җирлек территориясеннән хәзерге вакытта файдалануның картасы	4	1:10 000
2	Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләренең картасы (гамәлдәге нигезләмә)	4	1:10 000
3	Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре картасы (проект тәкъдиме)	4	1:10 000

1. КЕРЕШ

Әлеге проект Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 декабрендәге 38 номерлы Карары белән расланган Әлдермеш авыл җирлегенең Генераль планына алмашка эшләнә.

Проектның заказчысы - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Әлдермеш авыл җирлеге Башкарма комитеты.

Проектны эшләүче - "Максима" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте.

Проект 2040 елга кадәр исәп-хисап срогына әзерләнгән, гамәлгә ашыру этаплары ачыкланмаган.

1.1. Генераль планның максатлары һәм бурычлары

Генераль планны эшләүнең төп максатлары түбәндәгеләр:
- җирлекнең шәһәр төзелешен үстерүнең юнәлешен билгеләү һәм тәэмин итү;
- авыл җирлеген җирле дәрәҗәдәге шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү.

Проект бурычларына түбәндәгеләр керә:
- авыл җирлеге территориясен комплекслы бәяләү;
- торак пунктларның чикләрен корректировкалау;
- җирлек территориясен функциональ зоналаштыру, функциональ зоналарның параметрларын билгеләү;
- торак төзелеше мөмкинлеге булган территорияләрне билгеләү;
- җитештерү функциясен үстерү өчен территорияләрне билгеләү;
- транспорт инфраструктурасын үстерү;
- халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсен үстерү.

Генераль планның проект карарлары Әлдермеш авыл җирлегенең һәм Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше планнарын формалаштыру яки корректировкалау, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү, территорияне планлаштыру өчен нигез булып тора.

1.2. Комплекслы социаль-икътисадый үсеш планнары һәм программалары, шәһәр төзелеше документлары һәм файдаланыла торган материаллар турында белешмәләр

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Әлдермеш авыл җирлегенең әлеге генераль планы проекты Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының түбәндәге норматив хокукый актлары таләпләре нигезендә әзерләнде:

– Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 29.12.2004 ел, № 190-ФЗ;
– Россия Федерациясе Җир кодексы, 25.10.2001 ел, № 136-ФЗ;
– Россия Федерациясе Урман кодексы, 04.12.2006 ел, № 200-ФЗ;
– Россия Федерациясе Су кодексы, 03.06.2006 ел, № 74-ФЗ;
– 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон;
– РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 09 июнендәге 363 номерлы «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында» карары;
– 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законы;
– 2005 елның 31 январендәге 20-ТРЗ номерлы «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен

билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законы (2014 елның 30 декабрендәге 136-ТРЗ номерлы Закон редакциясендә);

– РФ Дәүләт комитетының 2002 елның 29 октябрендәге 150 номерлы "Шәһәр төзелеше документларын эшләү, килештерү, экспертиза һәм раслау тәртибе турында" карары (СНиП 11-04-2003) (29.12.2004ел, №190-ФЗ РФ Шәһәр төзелеше кодексына каршы килми торган өлешендә);

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы «Иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәт күрсәтүләр белән 2024 елга кадәр тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» (28.08.2019 редакциясендә) карары;

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 13 мартындагы 149 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы калдыклар белән эш итү өлкәсендә, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схема.

Генераль планны әзерләгәндә түбәндәге норматив документлар файдаланылды:

- СНиП 2.07.01-89*Актуальләштерелгән редакциясе СП 42.13330.2011. «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү»;

– СНиП 2.04.02-84* Актуальләштерелгән редакциясе СП 31.13330.2012 «Су белән тәэмин итү. Тышкы челтәрләр һәм корылмалар»;

– СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 «Санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлар»;

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 27 декабрендәге 1071 карары белән расланган Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары.

Әлеге проект түбәндәге социаль-икътисадый үсеш планнары һәм программалары нигезләмәләрен исәпкә алып әзерләнде:

– 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү Стратегиясен раслау турында» Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү Стратегиясе (алга таба - Стратегия);

– 2016 - 2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе.

Стратегия нигезендә Биектау муниципаль районы территориясе түбәндәге проектларны гамәлгә ашыруның территориясе булып тора: «Халыкны күчереп утырту Реновациясе», «Казан агломерациясе инженерлык инфраструктурасын үстерү һәм модернизацияләү», «Казанның шәһәр яны зонасы», «Сәнәгать зоналары редевелопменты», «Казан агломерациясенең транспорт инфраструктурасын үстерү», Казан икътисадый зонасында калдыклар белән идарә итү проекты.

Генераль план белән каралган чаралар Стратегиянең югарыда күрсәтелгән проектларына каршы килми.

Җирлек территориясендә гамәлдә булган территориаль планлаштыру документлары:

– Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 28 декабрендәге 2607-р Күрсәтмәсе белән расланган Россия Федерациясе сәламәтлек саклау өлкәсендә территориаль планлаштыру схемасы;

– Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 26 февралендәге 247-р номерлы Күрсәтмәсе белән расланган Россия Федерациясе югары һөнәри белем өлкәсендәге территориаль планлаштыру схемасы;

– Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 19 мартындагы 384-р номерлы Күрсәтмәсе белән расланган Россия Федерациясе федераль транспорт өлкәсендәге территориаль планлаштыру схемасы (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 1610-р 02.08.2018 ел Күрсәтмәсе белән расланган редакциядә);

– Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 13 августындагы 1416-р номерлы Күрсәтмәсе белән расланган торба үткәргеч транспорты өлкәсендә Россия Федерациясен

территориаль планлаштыру схемасы (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 2973-р 28.12.2017 ел Күрсәтмәсе белән расланган редакциядә);

– Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 11 ноябрендәге 2084-р номерлы Күрсәтмәсе белән расланган Россия Федерациясенең энергетика өлкәсендәге территориаль планлаштыру схемасы (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 2525-р 15.11.2017ел Күрсәтмәсе белән расланган редакциядә);

– Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 10 декабрендәге 615сс номерлы Указы белән расланган Оборона һәм иминлек өлкәсендә Россия Федерациясен территориаль планлаштыру схемасы;

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 21 февралендәге 134 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 09.07.2018 ел № 559 Карары белән расланган редакциядә);

– Биектау муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы 340 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасы (28.12.2016 № 117 Карары редакциясендә);

– Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 декабрендәге 38 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегенең Генераль планы.

Генераль планны әзерләгәндә түбәндәгеләр файдаланылды:

- Җирне дистанцион зоналарга бүлү материаллары - космос сурәте;
- Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең кадастр исәбе күрсәткечләре;
- Федераль дәүләт статистика хезмәте мәгълүматлары.

1.3. Җирлекнең кыскача характеристикасы

Әлдермеш авыл җирлеге Биектау муниципаль районының үзәк өлешендә урнашкан. Аның мәйданы 5455,146 га тәшкил итә.

Әлдермеш авыл җирлеге чиге 2005 елның 31 январендагы 20-ТРЗ номерлы «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән. (2014 елның 30 декабрендәге 136-ТРЗ номерлы Закон редакциясендә).

Җирлек чиге турында белешмәләр Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында бирелгән.

Җирлек территориясендә түбәндәге торак пунктлар урнашкан:

– Әлдермеш ав. (авыл җирлегенең административ үзәге);
– Өбрә ав.;
– Сая ав.

Даими халык саны 2019 елның 01 январенә 1063 кеше тәшкил итә, шул исәптән:

– Әлдермеш ав.: 526 кеше;
– Өбрә ав.: 144 кеше;
– Сая ав.: 393 кеше.

Мәгълүмат җирле үзидарә органнары белешмәләренә нигезләнеп күрсәтелгән.

2. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНЕҢ ХӘЗЕРГЕ ТОРЫШЫНА ҺӘМ ФАЙДАЛАНЫЛУЫНА АНАЛИЗ. ГЕНЕРАЛЬ ПЛАН ЧАРАЛАРЫН НИГЕЗЛӘҮ

2.1. Торак фонды

Гамәлдәге торыш

Җирлекнең торак төзелеше бер һәм ике катлы индивидуаль торак йортлар белән тәэмин ителгән, күпфатирлы торак йортлар юк.

Җирлекнең торак фондының гомуми күләме 2019 елның 01 январена мәгълүматлар буенча 45,8 мең кв.м торак мәйданы тәшкил итә, шул исәптән:

– Әлдермеш ав.: 24,3 мең кв. м торак мәйданы;

– Өбрә ав.: 6,4 мең кв. м торак мәйданы;

– Сая ав.: 15,1 мең кв. м торак мәйданы.

Мәгълүмат җирле үзидарә органнары белешмәләренә нигезләнеп күрсәтелгән.

Даими халыкның торак белән тәэмин ителеш күрсәткече 43,09 кв. м/кеше тәшкил итә.

Проект тәкъдиме

Генераль план белән, индивидуаль һәм күпфатирлы торак йортлар белән төзелешнең функциональ зоналарын формалаштыруга бәйле, гомуми мәйданы 147,88 га булган торак төзелеше мөмкинлеге булган территорияләрне бүлеп бирү каралган, шул исәптән:

– Әлдермеш ав. (көнбатыш өлештә): 13,01га;

– Әлдермеш ав. (төньяк өлештә): 81,65 га;

– Әлдермеш ав. (көньяк-көнбатыш өлештә): 49,65га;

– Өбрә ав. (төньяк-көнбатыш өлештә): 5,57 га.

Күрсәтелгән территорияләрне үзләштерү ихтималы булган торак фонды күләме арту 73,94 мең кв. м торак мәйданын тәшкил итәргә мөмкин. Торак фонды күләме артуын билгеләү шартлы кабул ителгән күрсәткечләргә нигезләнгән: индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлеге мәйданы 1500 кв. м (15 сутый) һәм 100 кв. м га тигез торак йорт мәйданы; СНиП 2.07.01-89* Актуальләштерелгән редакциядә СП 42.13330.2011 билгеләнгән коттедж төзелешләренең торак берәмлекләре составында төрле функциональ билгеләнештәге территорияләрнең норматив нисбәте (коттедж бистәсе өчен торак төзелеше өлеше 75 % тәшкил итә). «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү».

Торак төзелешен үстерү шулай ук төзелешнең тыгызлыгын арттыру һәм файдаланылмый торган территорияләрне үзләштерү исәбенә мөмкин.

2.2. Социаль, иҗтимагый һәм эшлекле объектлар

Гамәлдәге торыш

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә тәкъдим ителгән социаль, иҗтимагый һәм эшлекле билгеләнештәге төп объектлар һәм учреждениеләр турындагы белешмәләр 1 нче таблицада бирелгән. Әлеге белешмәләр 2019 елның 01 январена торыш буенча китерелгән.

1 нче таблица

Карталарда №	Исеме		Урнашкан урыны	Проект егәрлеге
МӘГАРИФ ОБЪЕКТЛАРЫ				
1	мәктәпкәчә белем бирү оешмасы	Балалар бакчасы	Әлдермеш ав., Хабибуллин ур, 2 й.	60 урын
2	гомуми белем бирү оешмасы	Урта гомуми белем бирү мәктәбе	Әлдермеш ав., Хабибуллин ур, 18 й.	250 урын

3	гомуми белем бирү оешмасы	Башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе	Сая ав., Юность ур., 14 й.	25 урын
-	өстәмә белем бирүне оешмасы	күрсәтелмәгән		
СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ОБЪЕКТЛАРЫ				
4	беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмасы бүлекчәсе	Фельдшер-акушерлык пункты	Әлдермеш ав., Хабибуллин ур, 2 й.	15 кил./см.
5	беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмасы бүлекчәсе	Фельдшер-акушерлык пункты	Сая ав., Юность ур.,	20 кил./см.
6	беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмасы бүлекчәсе	Фельдшер-акушерлык пункты	Өбрә ав., Тукай ур.	10 кил./см.
МӘДӘНИЯТ ОБЪЕКТЛАРЫ				
7	мәдәни-ял итү (клуб) тибындагы объект	Авыл мәдәният йорты	Әлдермеш ав., Ленин ур., 26 й.	180 урын
8	мәдәни-ял итү (клуб) тибындагы объект	Авыл мәдәният йорты	Сая ав., Светлая ав., 13 й.	150 урын
9	мәдәни-агарту билгеләнешендәге объект	Авыл китапханәсе	Әлдермеш ав., Хабибуллин ур, 18 й.	15000 экз. 12 урын
10	мәдәни-агарту билгеләнешендәге объект	Авыл китапханәсе	Сая ав., Светлая ав., 13 й.	7500 экз. 6 урын
11	мәдәни-агарту билгеләнешендәге объект	С. Сәйдәшев музее	Өбрә ав., Союзная ур.	–
ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ ОБЪЕКТЛАРЫ				
12	спорт объекты	Гомуми белем бирү мәктәбендә спорт залы	Әлдермеш ав., Хабибуллин ур, 18 й.	288 кв. м идән мәйданы
13	спорт корылмасы	Спорт мәйданчыгы	Әлдермеш ав.	1200 кв. м
14	спорт корылмасы	Спорт мәйданчыгы	Сая ав.	800 кв. м
ХАЛЫККА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ ОБЪЕКТЛАРЫ, СОЦИАЛЬ, ИҖТИМАГЫЙ ҺӘМ ЭШЛЕКЛЕ БИЛГЕЛӘНЕШЛЕ АДМИНИСТРАТИВ, ДИНИ ҺӘМ БАШКА ОБЪЕКТЛАР				
15	почта элемтәсе объекты	Почта элемтәсе бүлекчәсе	Әлдермеш ав., Ленин ур., 26 й.	–
-	җәмәгать тәртибен саклау объекты	күрсәтелмәгән		
16	сәүдә, җәмәгать туклануы объекты	Ваклап сату объектлары	–	–
17	административ бина	Авыл җирлеге Советының бинасы	Әлдермеш ав., Хабибуллин ур.	–
18	дини оешма объекты	Мәчет	Әлдермеш ав., Красный Маяк ур., 11 й.	–
19	дини оешма объекты	Мәчет	Әлдермеш ав, Гагарин ур., 8 й.	–
20	дини оешма объекты	Мәчет	Өбрә ав., Союзная ур.	–

21	дини оешма объекты	Мәчет	Сая ав., Юность ур., 17 й.	–

Халыкны хастаханә учреждениеләре, шулай ук ашыгыч медицина ярдәме белән тәэмин итү Биектау т.юл станциясе бистәсендә Үзәк район хастаханәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Әлдермеш авыл җирлегенең административ үзәгеннән Үзәк район хастаханәсенә кадәр 18 км чамасы ара (ашыгыч ярдәм машинасы килү вакыты - 18 мин. чамасы).

Авыл җирлеге халкының төп социаль, иҗтимагый һәм эшлекле билгеләнешендәге объектлар белән тәэмин ителешнең факттагы дәрәҗәсен бәяләү 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

Объектларның тибы	**Объектларның факттагы суммар егәрлеге**		**Тәэмин ителешнең факттагы дәрәҗәсе, %**	**Тиешле тәэмин ителешнең таләп ителгән дәрәҗәсенә ирешү өчен объектларның җитмәгән егәрлеге**	
	күрсәткеч	**үлчәү берәм.**		**күрсәткеч**	**үлчәү берәм.**
Гомуми белем бирү учреждениеләре	275	урын	250	–	урын
Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре	60	урын	217	–	урын
Өстәмә белем бирү учреждениеләре	0	урын	0	90	урын
Амбулатор-поликлиника учреждениеләре	45	сменага кил.	233	–	сменага кил.
Клуб учреждениеләре	330	урын	103	–	урын
Авыл китапханәләре	22500	экземпляр	282	–	экземпляр
Спорт заллары	288	идән мәйданы кв. м	77	84	идән мәйданы кв. м
Спорт (яссылыклы) корылмалар	2000	кв. м	96	73	кв. м

Хезмәт күрсәтү объектлары белән халыкның тәэмин ителеш дәрәҗәсен билгеләү СП 42.13330.2011 "Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү», шулай ук «2024 елга кадәр җәмәгать инфраструктурасы, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән гамәлгә ашырылды.

Проект тәкъдиме

Социаль, иҗтимагый һәм эшлекле билгеләнешле объектлар белән халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшырту өчен генераль планда кайбер объектларны урнаштыру күздә тотыла, алар турындагы белешмәләр 3 нче таблицада китерелгән.

3 нче таблица

Объектның статусы	**Объектның исеме**	**Төп характеристикалары**	**Урнашкан урыны**	**Урнаштыруның нигезләмәсе**
җирлекнең җирле әһәмияттәге	Спорт залы	проект егәрлеге – идән мәйданы 288 кв. м	Сая ав.	халыкның тиешле объектлар белән тәэмин ителешенең таләп ителгән дәрәҗәсенә ирешү; җирле үзидарә органнары инициативасы

	Яссылыклы корылма	проект егәрлеге - 162 кв. м	Өбрә ав.	халыкның тиешле объектлар белән тәэмин ителешенең таләп ителгән дәрәҗәсенә ирешү; җирле үзидарә органнары инициативасы
	Яссылыклы корылма **	проект егәрлеге - 2400 кв. м	Әлдермеш ав.	
муниципаль районның җирле әһәмияттәге	Өстәмә белем бирү учреждениеләре *	проект егәрлеге - 50 урын	Әлдермеш ав.	халыкның тиешле объектлар белән тәэмин ителешенең таләп ителгән дәрәҗәсенә ирешү; җирле үзидарә органнары инициативасы
	Өстәмә белем бирү учреждениеләре *	проект егәрлеге - 40 урын	Сая ав.	
	Балалар бакчасы белән берләштерелгән башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе	проект егәрлеге - 25 урын	Сая ав. (гамәлдәгесе урынына)	муниципаль районны территориаль планлаштыру Схемасы нигезләмәләрен гамәлгә ашыру; мәгариф объектлары белән халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшырту
	Башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе составындагы балалар бакчасы **	проект егәрлеге - 25 урын	Сая ав.	
	Фельдшер-акушерлык пункты	проект егәрлеге - 25 сменага кил.	Өбрә ав. (гамәлдәгесе урынына)	муниципаль районны территориаль планлаштыру Схемасы нигезләмәләрен гамәлгә ашыру; сәламәтлек саклау объектлары белән халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшырту

* чараны гамәлгә ашыру өчен Биектау муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү зарур

** күрсәтелгән объектны урнаштыруның максатка ярашлылыгы перспектив торак төзелеше территорияләрен үзләштерү нәтиҗәсендә халык санының планлаштырылган артуы белән аңлатыла.

Авыл җирлеге халкының социаль, иҗтимагый һәм эшлекле билгеләнешендәге төп объектлар белән тәэмин ителешнең, мондый объектларны урнаштыру чараларын, шулай ук таләп ителгән тәэмин ителеш дәрәҗәсенә ирешү буенча тәкъдимнәрне исәпкә алып, планлаштырылган дәрәҗәсен бәяләү 4 нче таблицада китерелгән.

4 нче таблица

Объектларның тибы	**Объектларның гамәлдәге һәм планлаштырылучы суммар егәрлеге**		**Чараларны гамәлләштерү нәтиҗәсендә тәэмин ителешнең йомгаклау дәрәҗәсе, %**
	күрсәткеч	**үлчәү берәм.**	
Гомуми белем бирү учреждениеләре	275	урын	250 * **

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре	85	урын	308 ***
Өстәмә белем бирү учреждениеләре	90	урын	100
Амбулатор-поликлиника учреждениеләре	45	сменага кил.	233 * **
Клуб учреждениеләре	330	урын	103 *
Авыл китапханәләре	22500	экз.	282 *
Спорт заллары	576	идән мәйданы кв. м	155 **
Спорт (яссылыклы) корылмалары	4562	кв. м	220 ***

* гамәлдәге объектларның куәте мондый объектларның таләп ителә торган куәтеннән исәп-хисап чорына артык булу белән бәйле тәэмин ителеш күрсәткече 100 %тан артык тәшкил итә

** тәэмин ителеш күрсәткече планлаштырылган объектларның типовой проектларын куллануга бәйле рәвештә 100 %тан артык тәшкил итә

*** тәэмин ителешнең йомгаклау дәрәҗәсе күрсәткече, генераль план белән социаль, иҗтимагый һәм эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру чаралары каралган булуга бәйле рәвештә, перспективалы торак төзелеше территорияләрен үзләштерү нәтиҗәсендә халык санын планлаштырыла торган арттыруны исәпкә алып, 100 %тан артып китә

Хезмәт күрсәтү объектлары белән халыкның тәэмин ителеш дәрәҗәсен билгеләү СП 42.13330.2011 "Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү», шулай ук «2024 елга кадәр җәмәгать инфраструктурасы, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән гамәлгә ашырылды.

Торак фондының 73,94 мең кв. м торак күләме арту ихтималы булганлыктан, даими халык санының якынча артуы 1590 кеше тәшкил итәргә мөмкин (гаилә коэффициенты 2,15 тигез кабул ителде).

Социаль, иҗтимагый һәм эшлекле билгеләнештәге объектларга халыкның мөмкин булган норматив ихтыяҗы турындагы белешмәләр 5 нче таблицада китерелгән.

5 нче таблица

Объектларның тибы	**Тәэмин ителешнең иң аз рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең норматив күрсәткече ***	**Объектларның кирәкле егәрлеге**	
		күрсәткеч	**үлчәү берәм.**
Гомуми белем бирү учреждениеләре	1000 кешегә 180 урын (демография турында белешмәләр булмаганда)	286	урын
Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре	1000 кешегә 180 урын (демография турында белешмәләр булмаганда)	286	урын
Өстәмә белем бирү учреждениеләре	мәктәп яшендәге балаларның 82 процентын колачлау	235	урын
Амбулатор-поликлиника учреждениеләре	1000 кешегә сменага 18,15 килү	28,86	сменага килү
Клуб учреждениеләре	1000 кешегә 300 урын	477	урын
Авыл китапханәләре	1000 кешегә 7,5 мең саклау берәмлеге	11925	мең саклау берәмлеге

	уку залында 1000 кешегә 6 урын	9,54	уку залында урын
Спорт заллары	10000 кешегә 3500 кв. м идән мәйданы	556,50	кв. м идән мәйданы
Спорт (яссылыклы) корылмалары	10000 кешегә 19500 кв. м	3100,50	кв. м

* Хезмәт күрсәтү объектлары белән халыкның тәэмин ителеш дәрәҗәсен билгеләү СП 42.13330.2011 "Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү», Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары, Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары, «2019 елга кадәр җәмәгать инфраструктурасы, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән гамәлгә ашырылды

Сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларының куәтләрен тиешле дәрәҗәдә арттыру мөмкинлеген ачыклау гамәлдәге норматив база әлеге объектларга ихтыяҗны объектив бәяләү бирми, дип күздә тотылмый. Аларны урнаштыру сорау барлыкка килгән саен билгеләнергә тиеш.

2.3. Сәнәгать предприятиеләре һәм объектлары

2.3.1. Сәнәгать җитештерүе объектлары

Гамәлдәге торыш

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә күрсәтелгән сәнәгать җитештерүе объектларына түбәндәге объектлар керә:

– Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба агач яру заводы;
– Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба агач эшкәртү җитештерүе;
– Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба бетон блоклар җитештерү предприятиеләре;
– Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба бетонга өстәмәләр җитештерү предприятиесе;
– Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба пластик савыт-саба җитештерү предприятиесе;
– Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба сыр заводы;
– Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба агач эшкәртү җитештерүе;
– Әлдермеш ав. көнбатышка таба сөт җитештерү буенча эшләми торган цех;
– Әлдермеш ав. көнбатышка таба су салу буенча эшләми торган предприятие.

Проект тәкъдиме

Җирлекнең җитештерү потенциалын күтәрү өчен җирле үзидарә органнары һәм кызыксынучы затлар ниятләренә ярашлы рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәләре исемлеге нигезендә сәнәгать җитештерүенең түбәндәге объектларын урнаштыру планлаштырыла:

– Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба товар бетоны, брусчаткалар һәм төзелеш блоклары җитештерү заводы (16:16:030402:160 җир кишәрлеге чикләрендә, территориянең мәйданы – 5,18 га);

– Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба кремний кушылмалары силикатлары нигезендә көнкүреш һәм техник химик продуктлар, төзелеш материалларына өстәмәләр җитештерү цехы (16:16:030402:217 җир кишәрлеге чикләрендә, территориненең мәйданы – 1,927 га);

– Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба чималны саклау өчен биналары булган җиләк-җимеш продукциясен эшкәртү һәм консервлау цехы, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге эшкәртү цехлары (16:16:030402:225 җир кишәрлеге чикләрендә, территориянең мәйданы – 3,0054 га);

– Өбрә ав. төньяк-көнчыгышка таба ярма җитештерү предприятиесе (16:16:030403:59 җир кишәрлеге чикләрендә);

– Өбрә ав. төньяк-көнчыгышка таба он җитештерү предприятиесе (16:16:030403:59 җир кишәрлеге чикләрендә);

– Өбрә ав. төньяк-көнчыгышка икмәк пешерү җитештерүе (16:16:030403:59 җир кишәрлеге чикләрендә).

Күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен Биектау муниципаль районының территориаль планлаштыру Схемасына үзгәрешләр кертү зарур.

Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектларның әйләнә-тирә мохит торышына тискәре йогынтысын киметү өчен локаль чистарту корылмалары төзү, әйләнешле су белән тәэмин итү системасын, сәнәгать калдыкларын чыгару һәм утильләштерү системасын оештыру, якын-тирәдәге территорияләрне максималь яшелләндерү максатка ярашлы.

Сәнәгать җитештерүенең эшләми торган предприятиеләре алып торган территорияләр сәнәгать җитештерүен үстерү өчен резерв территорияләр буларак карала.

2.3.2. Табу сәнәгате предприятиеләре һәм объектлары

Гамәлдәге торыш

Җирлек территориясендә тәкъдим ителгән нефть чыгару сәнәгате объектларына түбәндәгеләр керә:

- җирлекнең көнчыгыш өлешендә руда булмаган төзелеш материалларын чыгару карьеры.

Проект тәкъдиме

Табу сәнәгате предприятиеләрен урнаштыру генераль план белән тәкъдим ителми.

2.4. Авыл хуҗалыгы, балык тоту һәм балык үрчетү предприятиеләре һәм объектлары

2.4.1. Авыл хуҗалыгы җитештерүе, балык тоту һәм балык үрчетү предприятиеләре

Гамәлдәге торыш

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә түбәндәге авыл хуҗалыгы җитештерүе, балык тоту һәм балык үрчетү предприятиеләре тәкъдим ителде:

– Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба мөгезле эре терлек фермасы (егәрлеге: 50 башка кадәр);
– Әлдермеш ав. көнчыгышка таба мөгезле эре терлек фермасы (егәрлеге: 50 башка кадәр);
– Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба сарык фермасы (егәрлеге: 50 башка кадәр);
– Әлдермеш ав. көнбатышка таба үрдәк фермалары (егәрлеге: 24000 кош);
– Әлдермеш ав. көнчыгышка таба ат фермасы (егәрлеге: 50 башка кадәр);
– Әлдермеш ав. көньяк-көнбатышка таба умаралык;
– Өбрә ав. көньяк-көнчыгышка таба эшләмәүче мөгезле эре терлекләр фермасы.

Проект тәкъдиме

Җирле үзидарә органнары һәм җирлекнең җитештерү потенциалын күтәрү өчен кызыксынучы затлар ниятләренә караганда, агросәнәгать комплексы предприятиеләрен, төрле авыл хуҗалыгы җитештерүе төрләре белән, Өбрә ав.төньяк-көнчыгышка таба (планлаштырыла торган куәте: 50 башка кадәр) урнаштыру планлаштырыла.

Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектның әйләнә-тирә мохит торышына тискәре йогынтысын киметү өчен локаль чистарту корылмалары төзү, әйләнешле су белән тәэмин итү системасын оештыру, терлекчелек калдыкларын вакытлыча складлау урыннарын урнаштыру, якындагы территорияләрне максималь яшелләндерү максатка ярашлы.

Эшләмәүче авыл хуҗалыгы җитештерүе предприятиеләре алып торган территорияләр авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү өчен резерв буларак яисә авыл хуҗалыгына хезмәт күрсәтү функциясе буларак карала.

2.4.2. Авыл хуҗалыгын тәэмин итү объектлары

Существующее положение

Җирлек территориясендә тәкъдим ителгән авыл хуҗалыгын тәэмин итү объектларына түбәндәгеләр керә:

– Өбрә ав. төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы техникасын саклау гаражы;

– Өбрә ав. төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы продукциясен саклау складлары;

– Әлдермеш ав. көнбатышка таба авыл хуҗалыгы продукциясен саклау складлары;

– Әлдермеш ав. көнбатышка таба ягулык-майлау материаллары склады;

– Сая ав. төньяк өлешендә терлекләр карап тоту хуҗалыгы (егәрлеге: 50 башка кадәр);

– Әлдермеш ав. көнбатышка таба эшләмәүче авыл хуҗалыгы продукциясен саклау складлары;

– Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба эшләмәүче авыл хуҗалыгы продукциясен саклау складлары;

– Өбрә ав. көньяк-көнчыгышка таба эшләмәүче авыл хуҗалыгы продукциясен саклый торган складлар.

Проект тәкъдиме

Җирле үзидарә органнарының һәм кызыксынган затларның ниятләренә караганда, Әлдермештән төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы продукциясен саклау складын урнаштыру планлаштырыла.

Әйләнә-тирә мохит торышына урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектның җитди тискәре йогынтысы күздә тотылмый.

Авыл хуҗалыгын тәэмин итү объектлары биләгән территорияләр тиешле функцияне үстерү өчен резерв буларак карала.

2.5. Склад объектлары

Гамәлдәге торыш

Җирлектә булган склад объектларына түбәндәгеләр керә:

–Сая ав. төньяк-көнчыгышка җитештерү базалары.

Проект тәкъдиме

Склад объектларын урнаштыру генераль план белән тәкъдим ителми.

2.6. Зиратлар, махсус билгеләнешле объектлар

Гамәлдәге торыш

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә зиратлар турындагы тәкъдим ителгән белешмәләр җирле үзидарә органнары биргән мәгълүмат (хат) нигезендә 6 нчы таблицада китерелгән.

6 нчы таблица

Объект	Урнашкан урыны	Факттагы мәйданы, га	Җир кишәрлегенә каравы турында белешмәләр				Комментарий
			кадастр номеры	җирләр категориясе	рөхсәт ителгән файдалану төре	искәрмә	
Зират (гамәлдәге)	Әлдермәш ав. көньякка	5,7364	16:16:030103:29	Торак пунктлар җирләре	Зиратлар урнаштыру өчен	–	гамәлдәге җир кишәрлекләрен ең чикләрен зиратның факттагы чикләренә туры китерү таләп ителә; җир кишәрлеге характеристикаларын кирәклегә үзгәртү *
			16:16:030406:80	Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр	Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен	объект җир кишәрлеге өлешендә урнашкан	
			16:16:030406 кадастр кварталы өлеше			объектның бер өлеше чикләрендә җир кишәрлекләре турында белешмәләр булмаган территориядә урнашкан	
Зират (гамәлдәге)	Әлдермәш ав. көнчыгышка	2,2788	16:16:030404:24	Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр	Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен	объект җир кишәрлеге өлешендә урнашкан	гамәлдәге җир кишәрлекләрен ең чикләрен зиратның факттагы чикләренә туры китерү таләп ителә; * гамәлдәге җир кишәрлегенең чикләрен үзгәртү;
Зират (гамәлдәге)	Өбрә ав.көнчыгыш өлешендә	2,1082	16:16:030301:1	Торак пунктлар җирләре	Зиратлар урнаштыру өчен	–	гамәлдәге җир кишәрлекләрен ең чикләрен зиратның факттагы чикләренә туры китерү таләп ителә; җир кишәрлеге характеристикаларын кирәклегә үзгәртү *
			16:16:030403:5	Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр	Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен	объект җир кишәрлеге өлешендә урнашкан	
Иң салкын тәүлекләрнең һава температурасы, °С, тәэмин ителеше белән	0,98	- 41
	0,92	- 33
Иң салкын бишкөнлекнең һава температурасы, °С, тәэмин ителеше белән	0,98	- 33
	0,92	- 31
Һава температурасы, °С, 0,94 тәэмин ителеше белән		- 17
Һаваның абсолют минималь температурасы, °С		- 47
Иң салкын айның һава температурасының уртача тәүлеклек амплитудасы, °С		7,1
≤ 0 °С кимрәк уртача тәүлеклек һава температуралы чорның дәвамлыгы, һаваның тәүл., һәм уртача температурасы, °С,	дәвамлыгы, тәүл.	151
	уртача температура, °С	- 8,1
≤ 8 °С кимрәк уртача тәүлеклек һава температуралы чорның дәвамлыгы, һаваның тәүл., һәм уртача температурасы, °С,	дәвамлыгы, тәүл.	208
	уртача температура, °С	- 4,8
≤ 10 °С кимрәк уртача тәүлеклек һава температуралы чорның дәвамлыгы, һаваның тәүл., һәм уртача температурасы, °С,	дәвамлыгы, тәүл.	223
	уртача температура, °С	- 3,8
Иң салкын айның һаваның уртача айлык чагыштырма дымлылыгы, %		82
Иң салкын айда һаваның уртача айлык чагыштырма дымлылыгы 15 сәг., %		81
Ноябрь - март өчен явым-төшем күләме, мм		177
Декабрь - февраль өчен күпчелек җил юнәлеше		ЮЗ
Уртача тизлекнең гыйнвар аендагы румбалар буенча җилнең максималь тизлеге, м/с		4,1
Уртача тәүлеклек һава температурасы ≤ 8 °С белән чорда җилнең уртача тизлеге, м/с		3,1

16 нчы таблица

Елның җылы чорының климат параметрлары

Климат параметрлары	Күрсәткеч
Барометрик басым, гПа	1002
Һава температурасы, °С, 0,95 тәэмин ителеше белән	24
Һава температурасы, °С, 0,98 тәэмин ителеше белән	28
Иң җылы айның уртача максималь температурасы, °С	25,1
Һаваның абсолют максималь температурасы, °С	39
Иң җылы айның һава температурасының уртача тәүлеклек амплитудасы, °С	9,9
Иң җылы айның һаваның уртача айлык чагыштырма дымлылыгы, %	69
Иң салкын айда һаваның уртача айлык чагыштырма дымлылыгы 15 сәг., %	56
Апрель - октябрь өчен явым-төшем күләме, мм	368
Тәүлеклек максималь явым-төшем, мм	75
Июнь-август өчен күпчелек җил юнәлеше	С, З
Уртача тизлекнең июль аендагы румбалар буенча җилнең минималь тизлеге, м/с	0

Җирлек климаты параметрларын бәяләү СП 131.13330.2012 "Төзелеш климатологиясе" нең якындагы торак пункт (Казан шәһәре) өчен үтәлгән.

Һаваның еллык уртача температурасы 4,6°С.

Еллык уртача явым-төшем – 568,5 мм.

Җирлек территориясендә көньяк һәм көнбатыш юнәлештәге җилләр өстенлек итә.
Җилнең уртача еллык тизлеге 2,5 м/сек.

7.1.6. Инженерлык-геологик шартлар

Җирлек территориясендә тәкъдим ителгән куркыныч физик-геологик процессларга түбәндәгеләр керә:
- эрозия процесслары (ерганаклар, чокырлар) - су агымнары битләренә хас;
- сөзәклек процесслары (ишелү, коелу, шуышу) - аз үсеш алган;
- карст-суффозия процесслары (карст бүрәнкәләре, суффозия савытлары).

Җирлек территориясендә үзенчәлекле грунтлар күрсәтелмәгән.

7.1.7. Ландшафт, туфрак катламы, үсемлекләр

Җирлек территориясе Казан ландшафт районы чикләрендә урнашкан.
Туфракның характерлы типларына түбәндәгеләр керә:
- ачык соры урман туфраклары;
- аллювиаль туендырылган черемәле туфраклар;
- аллювиаль туендырылган черемәле карбонатлы;
- уртача көлсыман туендырылган черемәле.

Үсемлекләр капламын урманнар, болыннар, куаклыклар һәм авыл хуҗалыгы җирләре тәшкил итә.

7.2. Әйләнә-тирә мохит торышын бәяләү

7.2.1. Атмосфера һавасының торышы

Атмосфера һавасын пычратуның төп чыганаклары түбәндәгеләр:
- эшли торган сәнәгать предприятиеләре (агач яру заводы, агач эшкәртү җитештерүе, бетон блоклар җитештерү предприятиесе, бетонга өстәмәләр җитештерү предприятиесе, пластик савыт-саба җитештерү предриятиесе, Сая ав. төньяк-көнчыгышка сыр заводы);
– эшләүче авыл хуҗалыгы предприятиеләре (Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба мөгезле эре терлек фермасы, Әлдермеш ав. көнчыгышка таба мөгезле эре терлек фермасы, Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба сарык фермасы, Әлдермеш ав. көнбатышка таба үрдәк фермалары, Әлдермеш ав. көнчыгышка таба ат фермасы);
- машина-трактор парклары;
- автомобиль транспорты.

Җирлектә һава пробаларына лаборатор анализлар үткәрелми.

7.2.2. Су ресурсларының торышы

Су объектларын пычрату чыганаклары түбәндәгеләр:
- сәнәгать объектларының җитәрлек дәрәҗәдә чистартылмаган суларын оешкан төстә агызу;
- авыл хуҗалыгы предприятиеләре территорияләреннән чистартылмаган җыелып торган өске суларны агызу;
- торак пунктлар территорияләреннән чистартылмаган өске суларны агызу.

Су ресурсларын пычратуга шулай ук су саклау зоналары һәм өске су объектларының яр буе яклау полосалары режимын үтәмәү китерә, бу аларның җирлектә беркетелгән чикләре булмауга бәйле.

Сая ав. төньякка таба зират өлешенең өске су объектларындагы су саклау зонасында урнашуы тискәре факт булып тора.

Су җыю скважиналарының санитар-яклау зонасы чикләрендә урнашуы да тискәре факт булып тора.

Хәзерге вакытта җирлектә үзәкләштерелгән су чыгару системасы юк.

Җирлектә су ресурсларының пычрануы мониторингы үткәрелми.

7.2.3. Туфрак катламы һәм җир ресурсларының торышы

Авыл җирлеге территориясе өчен авыл хуҗалыгы җирләренең сөрелүе югары дәрәҗәдә, чокыр-ерганак челтәре белән кискәләнгән булуы, сөрүлекләрнең урман белән каплануы түбән булуы хас. Моның нәтиҗәсе булып, үсеш алган эрозия процесслары, туфракларның деградацияләнүе тора.

Җирлек территориясендә эрозиягә каршы чаралар үткәрелә, алар саклау урман утыртмаларын булдыру, туфракны саклаучы чәчүлекләр әйләнешен оештыруны, деградацияләнгән чәчүлекләрне табигый азык җирләренә күчерүне үз эченә ала.

Җирләрнең торышына аларның техноген пычрануы тискәре йогынты ясый: тозлану, пестицидлар, агып төшүче сулар, җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычрану.

Җирлек территориясендә туфрак пробаларын тикшерү үткәрелми.

7.2.4. Җитештерү һәм куллану калдыклары, биологик калдыклар

Биологик калдыклар чыганаклары түбәндәгеләр:

- себер язвасы үләксә базлары;
- биотермик чокырлар;
- зиратлар.

Аларның тискәре йогынтысына Өбрә ав. зур булмаган территорияләре дучар.

Терлекчелек калдыкларының барлыкка килүе гамәлдәге терлекчелек объектлары эшчәнлегенә бәйле. Терлекчелек объектларын утильләштерү тирес саклагычлар булмау һәм вакытлыча тирес туплау урыннары булмау сәбәпле җитәрлек үсеш алмаган. Тирес терлекчелек фермаларына якын җирдә урнашкан, ул җир һәм су ресурсларының пычрану куркынычын тудыра.

Сәнәгать калдыкларының барлыкка килүе эшләүче сәнәгать предприятиеләре (агач яру заводы, агач эшкәртү җитештерүе, бетон блоклар җитештерү предприятиесе, бетонга өстәмәләр җитештерү предприятиесе, пластик савыт-саба җитештерү предриятиесе, Сая ав. төньяк-көнчыгышка сыр заводы) эшчәнлеге белән бәйле.

Торак пунктлар территорияләренә коммуналь калдыклар барлыкка килү хас.

Җирлек территориясен санитар чистарту торак пунктларның контейнер мәйданчыклары белән тәэмин ителмәү сәбәпле таләп ителгән дәрәҗәгә туры килми.

7.2.5. Йогынтыларның физик факторлары

Халыкка йогынты ясауның физик факторларына электромагнит нурланышы, акустик һәм радиация тәэсире керә.

Җирлектә электромагнит нурланышы чыганаклары булып электр тапшыру линияләре, электр подстанциясе, элемтә объектлары тора. Электр-магнит кыры дәрәҗәсе рөхсәт ителгәннән кимрәк һәм халык өчен куркыныч тудырмый.

Тискәре акустик йогынты чыганакларына түбәндәгеләр керә:

- эшли торган сәнәгать предприятиеләре (агач яру заводы, агач эшкәртү җитештерүе, бетон блоклар җитештерү предприятиесе, бетонга өстәмәләр җитештерү предприятиесе, пластик савыт-саба җитештерү предриятиесе, Сая ав. төньяк-көнчыгышка сыр заводы);

– эшләүче авыл хуҗалыгы предприятиеләре (Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба мөгезле эре терлек фермасы, Әлдермеш ав. көнчыгышка таба мөгезле эре терлек фермасы, Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба сарык фермасы, Әлдермеш ав. көнбатышка таба үрдәк фермалары, Әлдермеш ав. көнчыгышка таба ат фермасы);

- автомобиль транспорты.

Авыл җирлегенең радиация шартлары күбесенчә табигый радиация фоны белән билгеләнә.

7.2.6. Яшел утыртмаларның торышы

Җирлек территориясендә тәкъдим ителгән яшелләндерү территорияләренә түбәндәгеләр керә:

- урманнар;

- елга һәм инеш тугайларына хас үзагачлы һәм куаклыклы үзе чәчелгән утыртмалар;
- махсус билгеләнештәге (зират территориясен) яшелләндерү;
– файдалануы чикләнгән (мәгариф объектларының яшелләндерелгән территорияләре) яшелләндерү;

Җирлектә гомуми файдаланудагы территорияне яшелләндерү юк.

Авыл җирлегенең яшелләндерелгән территорияләренең гомуми мәйданы 520,765 га тәшкил итә (гомуми мәйданнан 9,55 %).

Гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләрнең мәйданы СП 42.13330.2011 Актуальләштерелгән редакциясе СНиП 2.07.01-89*. «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» белән билгеләнгән минималь рөхсәт ителә торган норматив күрсәткеч кешегә 12 кв. м тигез. Шулай итеп, күрсәтелгән территорияләрнең мәйданы 1,28 га тәшкил итә.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә экологик ситуация тулаем алганда уңай санала.

7.3. Экологик ситуацияне оптимальләштерү буенча чаралар

Җирлектә экологик вәзгыятьне яхшырту өчен генераль план белән түбәндәге юнәлешләр буенча оештыру чаралары комплексын үткәрү тәкъдим ителә:

- әйләнә-тирә мохитне пычрату чыганакларын локальләштерү;
- һава бассейнын саклау;
- су ресурсларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану;
- җирлек фонлын саклау һәм җирлек территориясенең инженерлык саклавы;
- калдыклар белән эш итү системасын үстерү;
- халыкны физик йогынты ясауның физик факторларыннан яклау;
- яшелләндерү системасын үстерү.

Әлдермеш авыл җирлегенә карата түбәндәге чаралар актуаль:

- биологик калдыкларны җыю, утильләштерү һәм юкка чыгаруның ветеринария-санитария кагыйдәләренә үләксә базларын туры китерү;
- үләксә базларының санитар-яклау зоналары территорияләрендә микробиологик күрсәткечләрнең торышын тикшереп торуны гамәлгә ашыру, шул исәптән туфракка һәм грунт суларына лаборатор контроль оештыру;
- санитар-яклау зоналары күләмен кыскарту мөмкинлеген билгеләү өчен гамәлдәге яисә күздә тотыла торган торак төзелеше янәшәсендә урнашкан үләт базларының санитар-яклау зоналары проектларын эшләү;
- сәнәгать җитештерүе объектларында кулланыла торган технологик җиһазларны камилләштерү (агач яру заводы, агач эшкәртү җитештерүе, бетон блоклар җитештерү предприятиесе, бетонга өстәмәләр җитештерү предприятиесе, пластик савыт-саба җитештерү предриятиесе, Сая ав. төньяк-көнчыгышка сыр заводы);
– Әлдермеш ав. көнбатышка таба үрдәк фермаларының куәтен киметү һәм территориясен кыскарту, алга таба хәвефлелек классын үзгәртү һәм санитар-яклау зонасы күләмен киметү;

– эшләүче һәм урнаштыруга планлаштырылучы предприятиеләрнең санитар-яклау зоналары проектларын эшләү (агач яру заводы, агач эшкәртү җитештерүе, бетон блоклар җитештерү предприятиесе, бетонга өстәмәләр җитештерү предприятиесе, пластик савыт-саба җитештерү предриятиесе, Сая ав. төньяк-көнчыгышка сыр заводы; Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба мөгезле эре терлек фермасы, Әлдермеш ав. көнчыгышка таба мөгезле эре терлек фермасы, Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба сарык фермасы, Әлдермеш ав. көнбатышка таба үрдәк фермалары, Әлдермеш ав. көнчыгышка таба ат фермасы; Сая ав. төньяк-көнчыгышка һәм Өбрә ав. төньяк-көнчыгышка таба урнаштырылуга планлаштырыла торган сәнәгать предприятиеләре);

– предприятиеләрнең ташландыкларын киметү чараларын үтәве (шул исәптән тузаннан, газдан чистарту җайланмаларын җиһазлау);

- предприятиеләрдә йомык яки кире кайтару әйләнешле су белән тәэмин ителешне кертү;

– санитар-яклау зоналары территорияләрен тузанга, газга каршы торучан яшел үсентеләр токымнары белән максималь яшелләндерү;

– автомобиль юлларының юл өслеге сыйфатын яхшырту;

- пычраткычлар гамәлдә булган зоналарда атмосфера торышын мониторинглау тикшеренүләрен үткәрү;

–автотранспорт чараларын мотор ягулыгының экологик чиста төрләренә күчерү яки ягулыкның традицион төрләрен кулланучы автотранспорттан бүлеп чыгаруларны чистарту өчен катализаторлар һәм нейтрализаторлар кертү;

- физик тузуның югары дәрәҗәсенә ия булган гамәлдәге сүүткәргеч челтәрләрне реконструкцияләү;

– Әлдермеш ав. һәм Сая ав. үзәкләштерелгән су белән тәэмин ителмәгән территорияләрендә, шулай ук эшли торган һәм урнаштыруга планлаштырыла торган предприятиеләрдә яңа сүүткәргеч челтәрләр төзү;

– торак пунктларны агып төшүче суларны билгеләнгән нормативларга кадәр чистартып, яңгыр сулары һәм хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәрләре белән тәэмин итү;

– өске су объектларының су саклау зоналарында урнашкан торак төзелешнең беренче чиратта канализацияләү, чистарту корылмалары төзү;

– предприятиеләрне һәм торак пунктларны су белән тәэмин итү челтәрләренең техник торышын мониторинглау челтәрен, өске су объектларының гидромониторингын оештыру һәм үстерү;

–су саклау зоналары, яр буе яклау полосалары һәм өске су объектларының яр буе яклау полосалары һәм су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларыннан файдалануның махсус хокукый режимын үтәү;

– сәнәгать җитештерүенең гамәлдәге предприятиеләре өчен локаль чистарту корылмалары төзү (агач яру заводы, агач эшкәртү җитештерүе, бетон блоклар җитештерү предприятиесе, бетонга өстәмәләр җитештерү предприятиесе, пластик савыт-саба җитештерү предриятиесе, Сая ав. төньяк-көнчыгышка сыр заводы; Сая ав. төньяк-көнчыгышка һәм Өбрә ав. төньяк-көнчыгышка таба урнаштырылуга планлаштырыла торган сәнәгать предприятиеләре);

– эшли торган һәм урнаштыруга планлаштырылган авыл хуҗалыгы предприятиеләре өчен локаль чистарту корылмалары төзү (Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба мөгезле эре терлек фермасы, Әлдермеш ав. көнчыгышка таба мөгезле эре терлек фермасы, Сая ав. төньяк-көнчыгышка таба сарык фермасы, Әлдермеш ав. көнбатышка таба үрдәк фермалары, Әлдермеш ав. көнчыгышка таба ат фермасы; урнаштыру өчен планлаштырылган авыл хуҗалыгы җитештерүенең төрле төрләре булган агросәнәгать комплексы предприятиесе);

– су хуҗалыгы системаларының куркынычсыз торышын һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү, агып төшүче суларның су объектларына тискәре йогынтысын булдырмый калу (шул исәптән агып төшүче суларны чистартуның, чистарту корылмаларыннан явым-төшемне зарарсызландыруның һәм утильләштерүнең алдынгы технологияләрен кертү);

– өске су объектларының су саклау зоналарында урнашкан объектларны, сулыкларны пычранудан, ләм утырудан, чүпләнүдән һәм суларны саегудан саклауны тәэмин итә торган корылмаларны җиһазлау;

– өске су объектларының су саклау зоналары чикләрендә пестицидлар һәм агрохимикатлар куллануны тыю;

– эчәргә яраклы суның сыйфатын яхшырту (су җыю корылмаларын су әзерләү станцияләре, суны тимерсезләндерү һәм йомшарту системалары белән тәэмин итү);

- чишмәләрне төзекләндерү;

- җир асты суларын чыгару максатында җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияләрне рәсмиләштерү;

–су белән тәэмин итү чыганакларын, су саклау зоналарын һәм өске су объектларының яр буе яклау полосаларын санитар саклау зоналары чикләрен билгеләү, аларның чикләрен җирлектә махсус мәгълүмат тамгалары белән беркетү;

– Сая ав. төньякка таба зиратның бер өлешен өске су объектларының су саклау зонасында урнашуына бәйле рәвештә ябу;

– санитар-яклау зоналарында урнашкан су белән тәэмин итү чыганакларыннан эчәргә яраклы су белән тәэмин итү максатында җир асты суларыннан файдалануны булдырмау;

- якындагы туфрак катламын пычратуны булдырмау максатларында ягулык-майлау материалларын махсус поддоннар белән саклау мәйданчыкларын җиһазлау яки вак ташлы өемнән нигез ясау;

– авыл хуҗалыгы культураларын үстерүнең югары нәтиҗәле технологияләрен кертү юлы белән туфракның уңдырышлылыгын торгызу;

– җирләрне инвентаризацияләү һәм агрохимик тикшерү;

– игенчелекнең адаптив экологик-ландшафт системасын гамәлгә кертү;

– кулланыла торган агрохимикатлар күләмен киметү өчен туфрак эшкәртүнең ресурсларны сак тоту һәм экологик яктан куркынычсыз технологияләрен кертү;

– үсемлекләрне яклауның биологик чараларын куллану;

– игенчелекнең адаптив экологик-ландшафт системасын гамәлгә кертү;

– төзелеш барышында, линияле корылмалар урнаштырганда бозылган җирләрне рекультивацияләү;

– эрозиягә каршы чаралар үткәрү: көтүлекләр һәм печәнлекләр мәйданын арттыру, саклагыч утыртмалар мәйданын арттыру, туфракны эрозиягә каршы эшкәртү, яңгыр һәм кар суларының өске агымын оештыру;

- карстка каршы чаралар үткәрү (шул исәптән карст куышлыкларын һәм ярыкларны тампонлау, тозланган токымнарны һәм югарырак ятучы грунтларны цементация эремәләре инъекциясе белән беркетү, фундаментларның махсус конструктив чишелешләрен куллану, җир өслегенең утыруына һәм биналарның һәм корылмаларның деформацияләренә даими геодезик контроль);

– автомобиль юлларының кар белән каплануын киметү;

– торак пунктлар территорияләрен коммуналь калдыклар җыю контейнер мәйданчыклары һәм контейнерлар белән тәэмин итү;

– калдыкларны селектив җыюны оештыру, калдыкларны эшкәртүнең һәм утильләштерүнең яңа технологияләрен кертү;

– туфрак катламын анда агулы матдәләр һәм кушылмалар булуга, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен үстерүне күздә тота торган аз катлы төзелешне проектлаганда радиоактивлыкны тикшерүләр үткәрү;

–туфрак катламының теркәлгән яисә потенциаль пычрануы булган зоналарда кишәрлекләрне торак төзелешенә бүлеп бирүне туфракның экологик иминлеге турында бәяләмә яисә аны рекультивацияләү программасы булганда гына башкару;

– табигатьне саклау һәм санитар-эпидемиологик законнар таләпләре нигезендә төзелгән терлекчелек калдыкларын вакытлыча складларга урнаштыру урыннарын оештыру;

– биологик калдыкларны утильләштерү өчен терлекчелек фермаларын биогаз җайланмалары белән тәэмин итү;

– терлекчелек калдыкларын вермикомпостлау, ферментациянең гөмбә тизләткечләрен кулланып утильләштерү чаралары һәм башкалар;

– каты коммуналь калдыкларны Чыпчык авыл җирлегендәге гамәлдәге каты коммуналь калдыклар полигонына чыгаруны оештыру, алга таба Арча муниципаль районындагы муниципалитетара тармак комплексына транспортировкалау белән (Татарстан Республикасының калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схемасы нигезендә, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә);

–торак пунктлар территориясендә тавыштан саклау чараларын үткәрү (акустик экраннар урнаштыру, автомобиль юллары буйлап тавыштан саклаучы яшел үсентеләр полосалары булдыру, беренче эшелонда торак булмаган билгеләнештәге биналарны, тәрәзәләрнең тавыш изоляциясен файдалану);

– автомобиль юллары буйлап саклаучы яшелләндерүне оештыру;

– торак пунктлар территорияләрендә гомуми файдаланудагы яшелләндерүне оештыру;

– күчемсез мөлкәт объектларын проектлаганда, төзегәндә һәм эксплуатацияләгәндә һәм авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештырганда «яшел» стандартлар кертү һәм куллану;

– планлаштырыла торган объектларны урнаштырганда агач-куак үсентеләрен юкка чыгару урынына яшел утыртмаларны компенсацияләр белән тәэмин итү;

– махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау режимын үтәү (шул исәптән махсус сакланылучы табигать территорияләре булып торучы су объектларына агып төшүче суларны агызып чыгаруны булдырмау);

– радиоешлыклы диапазонның электромагнитлы нурланыш чыганакларының санитар-яклау зоналары проектларын эшләү;

– инженерлык коммуникацияләренең сак зоналары режимын үтәү;

– үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын саклау чараларын үткәрү (шул исәптән хайваннарның яшәү тирәлеген, аларның миграциясе юлларын, балыкларның маймыч үстерү урыннарына керә алуын саклау; хайваннарның транспорт чаралары астына эләгүен, балыкларның һәм башка су биологик ресурсларының су җыю корылмаларына эләгүен булдырмый торган конструктив чишелешләр куллану h.б.)

.

8. ТАБИГЫЙ ҺӘМ ТЕХНОГЕН ХАРАКТЕРДАГЫ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР ТУУ КУРКЫНЫЧЫ ТӨП ФАКТОРЛАРЫНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ ҺӘМ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ

8.1. Җирлек территориясенә йогынты ясарга мөмкин булган табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр чыганаклары исемлеге

Куркыныч геологик процесслар

1. Шуышулар

Җимергеч факторлар - тау токымнарының күчеше (хәрәкәте), сөзәклекнең астан юылуы, артык юешләнүе, сейсмик тирбәнешләр, катнаш массаларның механик басымы, бәрелүләр.

Нәтиҗәләре - корылмаларның зур булмаган зararланулары, инженерлык коммуникацияләренең сирәк җимерелүләре.

Куркынычны киметү чаралары – өслек сулары зонасында һәм аның янәшәсендәге территорияләрдә агып төшүне оештыру, җир асты суларын дренировкалау, тышкы йөкләнешләрне киметү, откосларны киртәләү һәм аларны астан юылудан һәм юудан саклау, терәк диварлар төзү, биеклектәге яшел үсентеләр утыртуны оештыру.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә шуышулар барлыкка килү мөмкинлеге Сола һәм Сая елгалары үзәне битләренә туры китерелгән.

СНиП 22-01-95 «Куркыныч табигый йогынтылар геофизикасы» нигезендә, җирлек территориясендә шуышулар барлыкка килү куркынычы категориясе «уртача куркыныч» дип бәяләнә».

2. Җир тетрәүләр

Җимергеч факторлар – җир кабыгында кинәт үзгәрешләр һәм өзеклекләр, җир асты карст бушлыкларының җимерелүе.

Нәтиҗәләре - биналар һәм корылмаларның җимерелүе, грунтларның сыеклануы һәм утыруы, шуышулар барлыкка килүе, плотиналарның җимерелүе һәм цунами барлыкка килү.

Куркынычны киметү чаралары - җир тетрәүләргә дучар булган территорияләрдә төзелешне чикләү, корылмаларны ныгыту, сейсмик мониторинг уздыру.

Россия Федерациясе территориясен сейсмик районлаштыру карталары һәм СП 14.13330.2014 нигезендә Әлдермеш авыл җирлеге территориясе 6 баллы зонага керә (В картасы).

Җир тетрәүләрнең барлыкка килү куркынычы категориясе СНиП 22-01-95 “Куркыныч табигый йогынты геофизикасы” буенча җирлек территориясендә “куркыныч” дип бәяләнә.

3. Сусаклагычлар ярларының абразиясе, эшкәртелүе

Җимергеч факторлар - су объектлары ярларына дулкыннар һәм прибой бәрүе, грунтларның җил белән очуы, юылуы.

Нәтиҗәләр - ярларның юылуы, яр буе территорияләренең авыл хуҗалыгы җирләреннән тартып алынуы, биналар һәм корылмаларның җимерелүе.

Куркынычны киметү чаралары - саклагыч корылмалар (дулкын җимерү диварлары, буналар, дулкын кайтаргычлар) төзү, ярлар участокларын тимер-бетон плитәләр һәм түшәкләр белән ныгыту, су асты сөзәклекләрен вал кую һәм юдыру, яр буе зонасында дым яратучы яшел үсентеләр утырту.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясенә сусаклагычлар ярларының абразиясе, эшкәртелүе характерлы түгел.

4. Карст

Җимергеч факторлар - тау токымнарының эрүе, токымнарның структурасы җимерелү, токым кисәкчекләренең күченүе (юылуы), җир өслегенең деформацияләнүе.

Нәтиҗәләре - сәнәгать һәм гражданнар корылмаларының деформацияләнүе, сәнәгать объектлары эшендә өзеклекләр, территориянең вакытлыча файдаланудан чыгуы.

Куркынычны киметү чаралары - өске суларның агып төшүен оештыру, җир асты суларын дренажлау, тышкы йөкләнешләрне киметү, биналарның һәм корылмаларның нигезләрен яклау.

Биектау муниципаль районының территориаль планлаштыру Схемасы материаллары буенча Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә карст күренешләре барлыкка килү төньяк һәм үзәк өлешләргә хас.

Карст барлыкка килү куркынычы категориясе СНиП 22-01-95 "Куркыныч табигать йогынтысы геофизикасы" буенча җирлек территориясендә "уртача куркыныч" дип бәяләнә.

5. Суффозия

Җимергеч факторлар - югарыда яткан грунтларның утыруы, тау токымнарының күчүе, җир өслегенең деформациясе.

Нәтиҗәләр - корылмаларның нигезләре йомшару һәм аларның деформацияләнүе һәм җимерелүе, сәнәгать объектлары эшендә өзеклекләр, территориянең вакытлыча файдаланудан чыгуы.

Куркынычны киметү чаралары - җир өсте суларын агызу, җир асты суларын дренировкалау, фильтрацион яклау пәрдәләре төзү, силикатлау, цементлау юлы белән бушлыкларны бетерү h.б.

Биектау муниципаль районының территориаль планлаштыру Схемасы материаллары буенча Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә суффозия барлыкка килү төньяк һәм үзәк өлешләргә хас.

Суффозия барлыкка килү куркынычы категориясе СНиП 22-01-95 "Куркыныч табигать йогынтысы геофизикасы" буенча җирлек территориясендә "уртача куркыныч" дип бәяләнә.

6. Лёсс токымнарының утыручанлыгы

Җимергеч факторлар - җир өслегенең деформациясе, грунтларның деформациясе.

Нәтиҗәләре - корылмаларның нигезләре йомшару һәм аларның деформацияләнүе һәм җимерелүе, сәнәгать объектлары эшендә өзеклекләр, территориянең вакытлыча файдаланудан чыгуы.

Куркынычны киметү чаралары - өске сулар агышын оештыру; җир асты суларын дренировкалау; трамбование, вибрация, җебетү юлы белән грунтларның утыру үзлекләрен бетерү; силикатлау, цемент эремәсе белән сеңдерү; биналарны конструктив көчәйтү.

Лёсс токымнарының утыручанлыгы барлыкка килү куркынычы категориясе СНиП 22-01-95 "Куркыныч табигать йогынтысы геофизикасы" буенча җирлек территориясендә "уртача куркыныч" дип бәяләнә.

7. Яссылык һәм ерганаклар эрозиясе

Җимергеч факторлар - грунтларның юылуы, чокырлар һәм ерганаклар ясалу.

Нәтиҗәләре - туфракның уңдырышлы катламы юк ителү; елгаларның һәм сулыкларның ләмләнүе; сугару һәм дренаж системаларының ләмләнүе; биналар һәм корылмаларның җимерелүе; юлларның юылуы.

Куркынычны киметү чаралары - өске сулар агышын оештыру, саклау урман полосалары булдыру, үсемлек белән чокыр битләрен нык ыгыту, ерымнарны йому һәм күмү.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә эрозия процессларының барлыкка килүе авыл хуҗалыгы җирләре территорияләренә кагыла.

Яссылык һәм ерганак эрозиясе барлыкка килү куркынычы категориясе СНиП 22-01-95 "Куркыныч табигый йогынты геофизикасы" буенча җирлек территориясендә "уртача куркыныч" дип бәяләнә.

8. Күперү

Җимергеч факторлар - бозлану, грунт күләменең механик үзгәрешләре.

Нәтиҗәләре - биналар һәм корылмаларның нигезләре зарарлану, инженерлык коммуникацияләре җимерелү.

Куркынычны киметү чаралары - биналарның һәм корылмаларның нигезен туфрак бозлану катлавыннан түбәнрәк томалау, өске сулар агышын оештыру, юллар төзегәндә саклау җайланмаларын (подложкалар, рәшәткәләрен) куллану.

Күперү барлыкка килү куркынычы категориясе СНиП 22-01-95 "Куркыныч табигый йогынты геофизикасы" буенча җирлек территориясендә "уртача куркыныч" дип бәяләнә.

Куркыныч гидрологик күренешләр һәм процесслар

1. Су күтәрелү

Җимергеч факторлар - грунт сулары биеклеге күтәрелү, грунт сулары агымының гидродинамик басымы, туфракның һәм грунтларның пычрануы (тозлануы), җир асты металл конструкцияләренең коррозиясе.

Нәтиҗәләре - биналарның һәм җир асты коммуникацияләренең подвалларын су басу, инженерлык коммуникацияләрендә аварияләр, биналарның һәм корылмаларның өлеше утыру һәм бүртү, шуышулар.

Куркынычны киметү чаралары - өске суларның агып төшүен оештыру, җир асты суларын дренировкалау.

Су күтәрелү барлыкка килү куркынычы категориясе СНиП 22-01-95 "Куркыныч табигый йогынты геофизикасы" буенча җирлек территориясендә "уртача куркыныч" дип бәяләнә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 27 апрелендәге 1001-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган язгы ташу чорында су басу (су күтәрелү) зонасына эләгүче Татарстан Республикасы торак пунктлары исемлеге нигезендә Әлдермеш авыл җирлегендә мондый торак пунктлар юк.

2. Су басу (суга бату)

Җимергеч факторлар - су агымы (агымы), гидросфераның, туфракның, грунтларның пычрануы.

Нәтиҗәләр - су чыгу, су басу, туфракның юылуы, туфракның агып торучы халәте барлыкка килү, корылмалар җимерелү, транспорт эшендә һәм тышкы эшләр уздыруда кыенлыклар, инженерлык коммуникацияләрендә аварияләр, юл-транспорт һәлакәтләре.

Куркынычны киметү чаралары – территорияләрне, биналарны һәм корылмаларны инженерлык саклавын оештыру; гидродинамик факторлар йогынтысына дучар булган территорияләрдән тыш объектларны урнаштыру; су күтәрелүгә һәм су басуга бәйле территорияләрдә потенциаль пычрану чыганакларын урнаштыруга юл куймау; су агымнары һәм сулыклар ярлары буенча саклагыч гидротехник корылмалар урнаштыру.

Су басу барлыкка килү куркынычы категориясе СНиП 22-01-95 "Куркыныч табигый йогынты геофизикасы" буенча җирлек территориясендә "уртача куркыныч" дип бәяләнә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 27 апрелендәге 1001-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган язгы ташу чорында су басу (су күтәрелү) зонасына эләгүче Татарстан Республикасы торак пунктлары исемлеге нигезендә Әлдермеш авыл җирлегендә мондый торак пунктлар юк.

3. Елга эрозиясе

Җимергеч факторлар - су ташкынының гидродинамик басымы, елга үзәненең деформациясе.

Нәтиҗәләре - юллар, коммуналь системалар, биналар һәм корылмалар җимерелүе; яр буе территорияләрендәге авыл хуҗалыгы җирләреннән файдалануның кире кайтарылмый торган югалтулар; урманны югалту.

Куркынычны киметү чаралары - яр ныгыту корылмалары төзү, елгаларда регуляция чараларын оештыру (елга үзәнен оештыру), барражлар системасы ярдәмендә елга төбенең буй авышлыкларын киметү, яр буе зонасында дым яратучы яшел үсентеләр утыртуны оештыру.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә елга эрозиясе барлыкка килү су агымнарына һәм аларның үзәннәренә туры килә.

Елга эрозиясе барлыкка килү куркынычы категориясе СНиП 22-01-95 “Куркыныч табигый йогынты геофизикасы” буенча җирлек территориясендә “уртача куркыныч” дип бәяләнә.

Куркыныч метеорологик күренешләр һәм процесслар

1. Көчле җил, давыллар, өермәләр

Җимергеч факторлар - җил агымы, җил йөкләнеше, аэродинамик басым, һаваның көчле киеренкелеге.

Нәтиҗәләре - бина һәм корылмаларның зарарлануы яки җимерелүе, транспорт эшендә һәм тышкы эшләр башкарудагы кыенлыклар, инженерлык коммуникацияләрендәге аварияләр, юл-транспорт һәлакәтләре, халыкның тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янау.

Куркынычны киметү чаралары - куркыныч производстволарны урнаштыруны чикләү, искергән яисә нык булмаган биналарны һәм корылмаларны демонтажлау, зарарланган һәм карт агачларны кисү, халыкны кисәтү һәм коткару хезмәтләре персоналын гадәттән тыш хәл шартларында гамәлләргә әзерләү буенча чаралар күрү.

Көчле җил, давыллар, өермәләр барлыкка килү куркынычы категориясе СНиП 22-01-95 “Куркыныч табигый йогынты геофизикасы” буенча җирлек территориясендә “уртача куркыныч” дип бәяләнә.

2. Көчле явымнар

Җимергеч факторлар - су ташкыны (агымы), территорияне су басу, кар йөкләнеше, җил йөкләнеше, кар көртләре, бозлавык йөкләнеше, бәрү.

Нәтиҗәләре - су басу, бина һәм корылмаларның зарарлануы яки җимерелүе, транспорт эшендәге һәм тышкы эшләр башкарудагы кыенлыклар, инженерлык коммуникацияләрендәге аварияләр, юл-транспорт һәлакәтләре, халыкның тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янау.

Хәвеф-хәтәрне киметү чаралары - территорияләрне, биналарны һәм корылмаларны инженерлык саклауны оештыру, үз вакытында фаразлау һәм халыкны кисәтү һәм коткару хезмәтләре персоналын гадәттән тыш хәл шартларында гамәлләргә әзерләү буенча чаралар күрү.

Табигый янгыннар

Җимергеч факторлар - ялкын, җылылык агымы, җылылык сугуы, һаваның болганчыклануы, атмосфераның, туфракның, грунтларның, гидросфераның пычрануы.

Нәтиҗәләре - урманнарның төтенләве, януы, халыкның тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янау, төзелешләргә зыян китерү, транспорт эшендә һәм тышкы эшләр уздыруда кыенлыклар, юл-транспорт һәлакәтләре.

Хәвеф-хәтәрне киметү чаралары - янгынга каршы өзеклекләр урнаштыру, янгын саклау бүлекчәләрен дислокацияләүне оптимальләштерү, корткычлардан һәм янгыннардан зыян күргән агачларны кисү.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә табигый (урман) янгыннарының килеп чыгу мөмкинлеге үзәк һәм көнчыгыш өлешләрдә зур урман массивларына туры килә. Дала һәм ландшафт табигый янгыннарының барлыкка килүе хас түгел.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында” 2014 елның 12 апрелендәге 236 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2016 елның 24 мартындагы 163 номерлы Карары нигезендә Әлдермеш авыл җирлегенең торак пунктлары һәм башка территорияләре һәм объектлары Татарстан Республикасы урман янгыннары янаган объектлар исемлегенә (торак пунктлар; гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләре; балаларның ялын оештыручы оешмалар һәм аларны сәламәтләндерү; икътисад объектлары, сәламәтләндерү оешмалары) керми.

Табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаган территорияләрнең чикләре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән.

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы биргән мәгълүматларда (2018 елның 18 апрелендәге 3428/Т-3-1-7 номерлы Хат), табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычына дучар булган территорияләр чикләре турында мәгълүмат юк.

Моннан тыш, «Су басу, су күтәрелү зоналарының чикләрен билгеләү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 18 апрелендәге 360 номерлы карары нигезендә су басу, су күтәрелү зоналары аларның чикләре хакындагы мәгълүматларның күчемсез мөлкәт Бердәм дәүләт реестрына кертелгән датадан билгеләнгән булып санала. Әлдермеш авыл җирлеге территориясен су басу зоналары чикләре турында Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында мәгълүмат юк.

8.2. Җирлек территориясендә, шулай ук җирлек территориясенә якын җирдә техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр чыганаклары исемлеге

Химик куркыныч объектлар

Территориясендә химик куркыныч объектлар булу нәтиҗәсе булып авария-химик куркыныч матдәләрне чыгару куркынычы янаган аварияләр тора.

Зыян салучы факторлар - куркыныч химик матдәләр түгелү яки бәреп чыгу.

Нәтиҗәләре - кешеләрнең, авыл хуҗалыгы хайваннарының һәм үсемлекләрнең һәлак булуы яисә химик зарарлануы; азык-төлекнең, азык чималының һәм азыкның химик зарарлануы; әйләнә-тирә табигать мохитенең химик зарарлануы.

Хәвеф-хәтәрне киметү чаралары - химия сәнәгате предприятиеләренең торышын мониторинглау, җитештерү процессларының технологик куркынычсызлыгын һәм мондый предприятиеләр җиһазларының эксплуатация ышанычлылыгын арттыру; химик аварияләр килеп чыгу мөмкинлеген фаразлау; авария резервуарларын, тозакларны, нишаларны химик куркыныч матдәләре булган саклагычлар астында урнаштыру.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә тәкъдим ителгән химик куркыныч объектларга түбәндәгеләр керә:

- Сая ав.төньяк-көнчыгышка пластик савыт-саба җитештерү предприятиесе (потенциаль куркыныч матдә: пластмассалар; зарарлы йогынты чикләре ачыкланмаган).

Янгын, шартлау куркынычы янаган объектлар

Территориясендә янгын, шартлау куркынычы янаган объектлар булу янгыннар һәм шартлауларга китерергә мөмкин.

Җимергеч факторлар - ялкын, очкыннар, шартлау, бәрмә дулкын, җылынган һава, токсик продуктлар, төтен.

Нәтиҗәләре - кешеләрнең сәламәтлегенә зыян китерү яки үлеме; биналарның һәм корылмаларның җимерелүе яки зарарлануы; халык хуҗалыгына, әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китерү.

Хәвеф-хәтәрне киметү чаралары - электр приборларын һәм электр челтәрләрен эксплуатацияләү тәртибен үтәү; янгын, шартлау куркынычы янаган объектларга караган предприятие хезмәткәрләренең янгынга каршы инструктажы; янгыннан ирекле саклауны оештыру; янмый торган матдәләр һәм материаллар куллану; янгынга каршы кагыйдәләрне һәм нормаларны үтәү.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә тәкъдим ителгән янгын куркынычы янаган объектларга түбәндәгеләр керә:

– Сая ав.төньяк-көнчыгышка пластик савыт-саба җитештерү предприятиесе (потенциаль куркыныч матдә: пластмассалар; зарарлы йогынты чикләре ачыкланмаган);

– Сая ав.төньяк-көнчыгышка агач яру заводы, агач эшкәртү җитештерүе (потенциаль куркыныч матдә: агач; зарарлау йогынтысы чикләре ачыкланмаган);

– Әлдермеш ав. көнбатышка ягулык-майлау материаллары склады (потенциаль куркыныч матдә: нефть эшкәртү продуктлары; зарарлау йогынтысы чикләре ачыкланмаган);

– табигый газ транспортлаучы торба үткәргечләр (потенциаль куркыныч матдә: газ; зараралау йогынтысы чикләре ачыкланмаган).

Радиацион куркыныч объектлар

Территориядә радиацион куркыныч объектлар булу нәтиҗәсе булып радиоактив матдәләр чыгару куркынычы булган аварияләр тора.

Җимергеч факторлар - радиоактив матдәләрнең һәм (яисә) ионлаштыручы нурланышларның чыгуы яки бәреп чыгуы.

Нәтиҗәләре - кешеләрнең, авыл хуҗалыгы хайваннарының һәм үсемлекләрнең, халык хуҗалыгы объектларының, шулай ук әйләнә-тирә табигать мохитенең ионлаштыручы нурланыш алуы яисә радиоактив пычрануы.

Куркынычны киметү чаралары - дозиметрик һәм радиометрик контроль алып бару, халык арасында йод профилактикасы үткәрү, пычранган җирлекне дезактивацияләү.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә радиацион-хәтәр объектлар юк.

Гидродинамик куркыныч объектлар

Территориядә гидродинамик куркыныч объектларның булуының нәтиҗәсе гидротехник корылмаларның басым фронты корылмаларының җимерелүе, бәреп чыгу дулкыны һәм һәлакәтле су басу зоналары барлыкка килүгә, шулай ук шлам саклагычларның өемнәре җимерелгәндә агулы матдәләр белән зараралануга бәйле мөмкин булган аварияләр тора.

Җимергеч факторлар – бәреп чыгу дулкыны, су ташкыны.

Нәтиҗәләре - һәлакәтле су басу; кешеләр, авыл хуҗалыгы хайваннары һәм үсемлекләрнең һәлак булуы; биналарның һәм корылмаларның җимерелүе яки зараралануы; җитештерү яки транспорт процессы бозылу; әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китерү.

Хәвеф-хәтәрне киметү чаралары – бәреп чыгу дулкыны йогынтысына дучар территориядә торак биналар һәм икътисад объектлары төзүне чикләү; вал төзү; җир асты суларын дренировка; яр буен ныгыту эшләрен үткәрү; бәреп чыгу дулкыны тизлеген киметергә сәләтле түбән кәүсәле урманнар утырту.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә гидродинамик куркыныч объектлар юк.

Куркыныч йөкләрне ташыганда транспортта куркыныч хәлләр

Куркыныч йөкләрне ташыганда транспорттагы хәвефле хәлләргә кертәләр:

1. Куркыныч йөкләрне ташыганда автомобиль транспортында мөмкин булган аварияләр

Зыян китерүче факторлар - бәрелү, транспорт чарасына ут кабу; ташый торган янгын куркынычлы йөкнең януы; ташый торган шартлау куркынычы булган йөкләрнең шартлавы һәм януы; ташый торган куркыныч химик йөкнең агуы (чәчрәве, парга әйләнүе).

Нәтиҗәләре - кешеләрнең травма алуы һәм үлеме, янгыннар, әйләнә-тирә мохитнең пычрануы, транспорт чараларына зыян килү, ташый торган йөкләрнең юкка чыгарылуы.

Куркынычны киметү чаралары - куркыныч йөкләрне ташу өлкәсендә норматив документлар таләпләрен үтәү, куркыныч йөк турында мәгълүмат (мәгълүмат таблицалары, авария һәм мәгълүмати карточкалар) бирү системаларын куллану, юл шартларын исәпкә алып, автотранспорт чараларының хәрәкәт тизлеген чикләү, махсус җиһазландырылган транспорт чараларын куллану, йөкләр ташу өчен махсус җиһазландырылган тара куллану.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә «Каменка - Дөбъяз - Олы Әтнә», «М7«Идел» - Әлдермеш» һәм «Әлдермеш - Чуашлы» транзит автомобиль юллары узу сәбәпле, шулай ук җирлек территориясендә пластик савыт-саба җитештерү предприятиесе, ягулык-майлау материаллары склады урнашуга бәйле рәвештә куркыныч йөкләр ташуда аварияләр барлыкка килү ихтималы

характерлы (потенциаль куркыныч матдәләр: нефть эшкәртү продуктлары, аммиак, сыекландырылган газ, кислоталар һәм башкалар; зарарлы йогынты чикләре билгеләнмәгән).

2 Куркыныч йөкләрне ташыганда тимер юл транспортында ихтимал авариял ә р

Зыян китерүче факторлар - бәрү, транспорт чарасына ут кабу; ташый торган янгын куркынычлы йөкнең януы; ташый торган шартлау куркынычы булган йөкләрнең шартлавы һәм януы; ташый торган куркыныч химик йөкнең агуы (чәчрәве, парга әйләнүе).

Нәтиҗәләре - кешеләрнең травма алуы һәм үлеме, янгыннар, әйләнә-тирә мохитнең пычрануы, транспорт чараларына зыян килү, тимер юлларның җимерелүе, ташый торган йөкләрнең юкка чыгарылуы.

Куркынычны киметү чаралары - куркыныч йөкләрне ташу өлкәсендә норматив документлар таләпләрен үтәү, куркыныч йөк турында мәгълүмат бирү системаларын куллану, махсуслаштырылган вагоннар һәм контейнерлар куллану, йөкләрне махсус әзерләү һәм төргәкләү, тиешле белгечләр тарафыннан йөкләрне юл буе озату һәм саклау.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә куркыныч йөкләрне ташуда тимер юл транспортында авариял ә р барлыкка килү ихтималы характерлы түгел.

3. Куркыныч йөкләрне ташыганда су транспортында ихтимал авариял ә р

Зыян китерүче факторлар - бәрү, транспорт чарасына ут кабу; ташый торган янгын куркынычлы йөкнең януы; ташый торган шартлау куркынычы булган йөкләрнең шартлавы һәм януы; ташый торган куркыныч химик йөкнең агуы (чәчрәве, парга әйләнүе).

Нәтиҗәләре - кешеләрнең һәм хайваннарның имгәнүе һәм һәлак булуы, янгыннар, әйләнә-тирә мохитнең пычрануы, транспорт чараларына һәм гидротехник объектларга зыян килү, ташый торган йөкләрнең юкка чыгарылуы.

Куркынычны киметү чаралары – куркыныч йөкләрне ташу өлкәсендә норматив документлар таләпләрен үтәү, куркыныч йөк турында мәгълүмат бирү системаларын куллану, йөкләр ташу өчен махсус җиһазландырылган тара куллану.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә куркыныч йөкләрне ташуда су транспортында авариял ә р барлыкка килү ихтималы характерлы түгел.

4. Куркыныч йөкләрне ташыганда торба үткәргеч транспортында ихтимал авариял ә р

Җимергеч факторлар – хәтәр химик яки шартлау куркынычы булган матдәләр басымы астында бәреп чыгу яки агу, шартлау.

Нәтиҗәләре - кешеләрнең һәм хайваннарның имгәнүе һәм үлеме, әйләнә-тирә мохитне пычрату, икътисадка зыян китерү.

Хәвефне киметү чаралары - торба үткәргечләрнең физик яктан таушалган яисә мораль яктан искергән участокларын үз вакытында ремонтлау, реконструкцияләү һәм аларга техник хезмәт күрсәтү, торбаүткәргечләрнең торышын мониторинглау системасын оештыру, торбаүткәргечләрне эксплуатацияләүнең технологик ысулларын куллану, торбаүткәргечләрне коррозиядән саклауның нәтиҗәле ысулларын куллану.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә торба үткәргеч транспортында куркыныч йөкләрне ташыганда авариял ә р барлыкка килү ихтималы характерлы түгел.

Техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаган территорияләрнең чикләре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән.

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы биргән мәгълүматларда (2018 елның 18 апрелендәге 3428/Т-3-1-7 номерлы Хат), техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычына дучар булган территорияләр чикләре турында мәгълүмат юк.

8.3. Җирлек территориясендә биологик-социаль характердагы гадәттән тыш хәлләр чыганаклары исемлеге

Биологик-куркыныч объектлар

Зарар китерүче факторлары –хәтәр биологик матдәләр таралу.

Нәтиҗәләре - кешеләрнең, авыл хуҗалыгы хайваннарының һәм үсемлекләрнең биологик йогышлы авыру йоктыруы яисә һәлак булуы; әйләнә-тирә табигать мохитен биологик йоктыру.

Куркынычны киметү чаралары - санитария-гигиена һәм санитария-эпидемиология кагыйдәләрен, технологик һәм оештыру-техник таләпләрне үтәү; фармацевтика һәм микробиология сәнәгате предприятиеләренең торышын мониторинглау, җитештерү процессларының технологик куркынычсызлыгын һәм мондый предприятиеләр җиһазларының эксплуатацияләү ышанычлылыгын арттыру.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә тәкъдим ителгән биологик-куркыныч объектларга түбәндәгеләр керә:

- Өбрә ав. көньяк-көнбатышка таба биотермик чокыр;

– Әлдермеш ав.көньякка таба себер язвалы үләксә базы.

Йогышлы авыруларның табигый учаклары

Зарар китерүче факторлары – инфекцияле авыру (патогенлы микроорганизмнар).

Нәтиҗәләре - эпидемияләр, эпизоотияләр, эпифитотияләр.

Куркынычны киметү чаралары - карантин, обсервация, йогышлы авыруларны изоляцияләү, санитария һәм эпидемиологик күзәтчелекне уздыру, территорияне санитар саклауны оештыру, эпизоотиягә каршы чаралар үткәрү, ветеринария-санитария күзәтчелеген оештыру.

Җирлек территориясендә йогышлы авыруларның табигый чыганаклары юк.

Биологик-социаль характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаган территорияләрнең чикләре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән.

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы биргән мәгълүматларда (18.04.2018№ 3428/Т-3-1-7 Хат), биологик-социаль характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычына дучар булган территорияләр чикләре турында мәгълүмат юк.

8.4. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар исемлеге

Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасының торышы турындагы белешмәләр, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү объектларының урнашуы турындагы белешмәләр әлеге томның «Җирлек территориясенең бүгенге торышы һәм файдаланылуына анализ. Генераль план чараларын нигезләү» дип аталган 2 кисәкнең «Инженерлык инфраструктурасы һәм коммуналь хезмәт күрсәтү»дигән 2.9 бүлегендәге 2.9.9 “Янгын куркынычсызлыгы” бүлекчәсендә китерелгән.

Әлдермеш авыл җирлеге территориясе өчен актуаль булган янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларына кертергә кирәк:

– янгынның участтан читкә таралуын чикләүне тәэмин итә торган күләмле-планлаштыру чишелешләрен һәм чараларны куллану;

–эвакуация юлларын, янгынны ачыклау системаларын (янгын сигнализациясе җайланмаларын һәм системаларын) төзү;

–биналарның һәм корылмаларның янгын куркынычы янаган конструктив янгын куркынычсызлыгы классына туры килә торган ут чыдамлыгы һәм янгын куркынычы классына туры килә торган төп төзелеш конструкцияләрен куллану;

– төзелеш корылмаларының утка каршы ныклыгы чикләрен арттыру өчен уттан саклау составларын (шул исәптән антипиреннарны һәм уттан саклау буяуларын) һәм төзелеш материалларын куллану;

– шартлауга каршы яклау системаларын технологик җиһазлауга урнаштыру;
– автомат һәм (яисә) автоном янгын сүндерү җайланмаларын куллану;
– янгыннан саклау бүлекчәләре эшчәнлеген оештыру;
– янгын урынына янгын сүндерү техникасының тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итү;
– янгын турында халыкка элемтә һәм хәбәр итүне тәэмин итү;
– халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне оештыру һәм янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә пропаганда.

9. ТӨП ТЕХНИК-ЭКОНОМИК КҮРСӘТКЕЧЛӘР

17 нче таблица

№ т/б	Күрсәткечнең исеме	Үлчәү берәмлеге	Гамәлдәге торыш	Хисап срогы
1	Җирлек мәйданы	га	5455,146	5455,146
2	Торак пунктларның территорияләре мәйданы	га	238,023	346,138
	шул исәптән:			
	Әлдермеш ав.	га	116,091	232,885
	Өбрә ав.	га	39,91	41,846
	Сая ав.	га	82,023	71,406
3	Даими халыкның саны	чел.	1063	2653 *
4	Торак фондының күләме	тыс. кв. м	45,8	119,74 *
5	Территорияләр балансы **			
	индивидуаль торак йортлар белән төзелеш территорияләре	га / %	164,624 / 3,02	314,526 / 5,77
	социаль, иҗтимагый һәм эшлекле билгеләнештәге объектлар территорияләре	га / %	4,4 / 0,08	4,4 / 0,08
	гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләре территорияләре	га / %	10,97 / 0,2	10,97 / 0,2
	рекреацион билгеләнеш территорияләре	га / %	5,38 / 0,1	5,38 / 0,1
	сәнәгать предприятиеләренең җитештерү территорияләре:			
	сәнәгать җитештерүе предприятиеләре территорияләре	га / %	15,029 / 0,28	29,213 / 0,54
	чыгару сәнәгате предприятиеләре территорияләре	га / %	7,05 / 0,13	0,0 / 0,0
	авыл хуҗалыгы предприятиеләре территорияләре һәм авыл хуҗалыгын тәэмин итү объектлары	га / %	47,941 / 0,88	55,294 / 1,01
	инженерлык инфраструктурасы һәм коммуналь хезмәт күрсәтү объектлары территорияләре	га / %	1,009 / 0,02	1,009 / 0,02
	транспорт инфраструктурасы объектлары территорияләре	га / %	62,386 / 1,14	67,528 / 1,24
	махсус билгеләнешле территорияләр	га / %	0,055 / 0,0	0,055 / 0,0
	зиратлар территорияләре	га / %	19,345 / 0,35	20,867 / 0,38
	торак пунктларның яшелләндерелгән территорияләре	га / %	14,192 / 0,26	15,721 / 0,29
	авыл хуҗалыгы җирләре:			
	чәчүлекләр	га / %	4225,547 / 77,46	4084,838 / 74,88
	көтүлекләр, печәнлекләр, ятмалар	га / %	314,531 / 5,77	302,912 / 5,55

	урманнар, башка үсентеләр:			
	урманнар	га / %	350,236 / 6,42	350,236 / 6,42
	куаклыклы үсемлекләр	га / %	156,337 / 2,87	170,831 / 3,13
	сулыклар:			
	өске су объектлары	га / %	21,367 / 0,39	21,367 / 0,39
	торак пунктларның башка территорияләре	га / %	34,747 / 0,64	0,0 / 0,0

*торак төзелеше территорияләре мәйданнарының артуын исәпкә алып, якынча күрсәткечләр күрсәтелгән

**территорияләр балансы исәпләрендә гамәлдәге нигезләмәдә фактик функциональ файдаланудагы территорияләр мәйданнары исәпкә алынган, территорияләр балансын исәпләп чыгару срогына - функциональ зоналар тарафыннан тәкъдим ителгән планлаштырыла торган функциональ файдаланудагы территорияләр мәйданнарына исәпләгәндә